

ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ

# СӘЯХӘТНАМӘЛӘР

«МИЛЛИ КИТАП»

**ТАТАР АРХЕОГРАФИЯСЕ**

# СӘЯХӘТНАМӘЛӘР

Казан
«Милли китап» нәшрияты
2011

УДК 821.512.145 + 902/904
ББК 84 (2Рос=Тат) + 63.2
С 97

*Төзүчесе, басмага әзерләүче*
*һәм махсус мәкаләләр авторы –*
*археограф, текстолог*
Раиф Мәрданов

**Сәяхәтнамәләр** / төз. Мәрданов Р.Ф. – Казан: «Милли китап» нәш-
С 97 рияты, 2011. – 84 б. – («Татар археографиясе» сериясе; 8 нче китап).

ISBN 978-5-88473-061-8

Бу җыентыкта дүрт сәяхәтнамә: татар сугышчысының 1756 елгы язмасы, 1937-38 елларга караган Кырым сәяхәтнамәсе, 1945 һәм 1953 еллардагы хаҗ сәфәрләрен тасвирлаган текстлар туплап бирелде.

ISBN 978-5-88473-061-8

УДК 821.512.145 + 902/904
ББК 84 (2Рос=Тат) + 63.2

© Мәрданов Р.Ф., 2011
© «Милли китап» нәшрияты, 2011

## Төзүчедән

Сәяхәтнамәләр язу татар халкының рухи мирасында борынгыдан ук килә. Бу тарихи-әдәби, документаль жанр гасырлар дәвамында үзенчәлекле бер рәвеш алган.

Фәндә мәгълүм татар сәяхәтнамәләре жанрындагы язма истәлекләрдән Исмәгыйль Бикмөхәммәт улының 1751 елда Һиндстанга булган сәфәренең сәяхәтнамәсе, Мөхәммәтәмин Гомәр улының 1780 еллардагы Шәрык сәяхәтнамәсе иң мәшһүрләрдән. Шулай ук Шиһабетдин Мәрҗанинең (1818–1889) XIX йөздә Төркия һәм гарәп илләренә сәяхәтнамәсе, Заһир Бигиевнең (1870–1902) «Мәвараэннәһердә сәяхәт»е, XX йөз башында Фатыйх Кәриминең (1870–1937) «Кырымга сәяхәт» һәм «Европа сәяхәтнамәсе» хезмәтләре, Садретдин Максудиның (1878–1957) «Англиягә сәяхәт»е һәм башкалар билгеле. Болардан тыш, XIX һәм XX йөзләрдәге хаҗ сәфәрләрен тасвирлаган сәяхәтнамәләр бар. Дөрес, татар хаҗиларының сәяхәтнамәләре әлегәчә фәндә тиешенчә өйрәнелмәгән. Хаҗ сәяхәтнамәләре, икенче төрле әйткәндә – хаҗнамәләр совет хакимияте дәверендә дә дәвам иткән. Ислам дине өчен авыр елларда да әби-бабаларыбыз хаҗнамәләрне элекке традиция буенча күчереп язганнар һәм халык арасында таратканнар.

Татарстан Милли китапханәсенең Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә дә татар сәяхәтнамәләренең XVIII–XX гасыр кульязма нөсхәләре саклана. Мәсәлән, «Исмәгыйль ага сәяхәтнамәсе»нең XIX йөзгә нисбәтле бер, ә «Мөхәммәтәмин сәяхәтнамәсе»нең ике кульязмасы, шулай ук бүтән сәяхәтнамәләр һәм юльязмалар бар.

Бу җыентыкка сәяхәтнамә жанрына караган истәлекләрдән китапханәдә саклана торган дүрт кульязманың текстлары туплап бирелде. Аларның беренчесе татар сугышчысының 1756 елгы юльязмасы, ә калган өчесе XX гасырның совет дәверенә – 1937-38, 1945 һәм 1953 елларга карый. 1937-38 елларда язылганы Кырымга сәфәрне тасвирлаган, ә соңгы икесе – хаҗнамәләр.

Хажнамәләрнең берсендә, совет хөкүмәтенең рөхсәте белән, Эчке Россия һәм Себер мөселманнарының Диния нәзарәте рәисе мөфти Габдрахман Зәйнулла улы Рәсүли (1881–1950) җитәкчелегендә 1945 елның ноябрь аенда хаҗга бару вакыйгасы кыскача тасвирланган. Мөфти Г.Рәсүлинең Бөек Ватан сугышы вакытында, 1943 елда СССР мөселманнары исеменнән Сталинга мөрәҗәгать итүе һәм Кызыл Армиягә ярдәм йөзеннән мөселманнардан танк колоннасы төзү өчен акча җыеп бирүе совет дәүләтенең Исламга карата сәясәтен берникадәр йомшартуга китергән. Дәһшәтле сугыш беткән елда ук совет илендә яшәгән мөселманнарның хаҗ сәфәренә фатиха биреп, хөкүмәт, үзенчә, киң күңеллелек күрсәткән.

Икенче хаҗнамәдә бөтен СССРдагы мөселман дин әһелләреннән 18 кешенең 1953 елда хаҗга баруы турында язылган. Анда СССРның Европа өлеше һәм Себер мөселманнары Диния нәзарәтенең мөфтие Шакир Шәйхелислам улы Хәялетдинов (1890–1974) җитәкчелегендә Казан, Уфа, Мәскәү һәм башка шәһәрләрдәге, Урта Азия республикаларындагы дин әһелләренең хаҗ сәфәре тасвирланган.

Җыентыкка текстларны хронологик тәртип буенча урнаштырдык. Баштагы ике текстка карата өстәмә мәгълүматлар һәм кайбер нәрсәләргә аңлатма бирү ихтыяҗы булганлыктан, аерым кереш мәкаләләр яздык.

Һәр кульязманың китапханәгә кайчан һәм кемнән алынуы турындагы һәм башка мәгълүматлар җыентык ахырында бирелгән кульязма тасвирларында язылды.

Татар кульязма традициясенең дәвамчанлыгын күзаллау өчен, XX гасырга караган өч текстның орфографик үзенчәлекләрен сакладык.

## XVIII ГАСЫР ТАТАР СУГЫШЧЫСЫНЫҢ ЮЛЪЯЗМАСЫ

Сугышка алынган татар кешесе тарафыннан теркәлгән бу тарихи язма начар хәлдәге өч кәгазьдә сакланып калган. Язулары тоныкланган һәм начар таныла. Кулъязманың палеографик үзенчәлекләре һәм орфографик хаталары да укылышны катлауландыра.

Текстның безнең тарафтан укылган хәтле өлеше гади һәм аңлаешлы телдә язылган. Эчтәлеге һәм мәгълүматы ягыннан кызыклы булган бу юлъязмада 1756 елда хәрби походка чыккан мишәр-татар гаскәренең көнбатышка, Европа тарафына бару вакыйгасы тасвирланган. Юлъязма авторы ерак юлга чыккан биш йөз кешелек мишәр командасында катнашкан билгесез бер татар сугышчысы. Ул гаскәрнең тарихта «Җидееллык сугыш» дигән исем астында билгеле сугышка барышлары булуы аңлашыла. Пруссиянең Бөекбритания һәм Португалия белән берләшеп, Швеция, Саксония, Франция һәм Испаниягә каршы 1756–1763 еллардагы сугыш хәрәкәтләрендә Россия дә катнашкан була. Түбәндәге юлъязмада шул сугышка катнашу өчен ерак походка чыккан мишәр-татар гаскәриләренең маршруты һәм юлда күргәннәре өлешчә хикәяләнгән.

Язылганнардан аңлашылуынча, әлеге поход хәзерге Башкортстан башкаласы Уфа шәһәре яныннан башланып, Татарстанның көньяк-көнчыгыш һәм көньяк өлешләре аша Самара өлкәсенең төньягыннан узып, Самара каласына юнәлгән. Самара янында Идел елгасын кичеп, хәзерге Ульяновск, Тамбов, Липецк, Курск өлкәләре территорияләрен узып, Украинаның Чернигов өлкәсенә кадәрге маршрут кыскача теркәлгән.

Юлъязмада тарихи мәгълүмат бирелү белән беррәттән, сәяхәтнамә жанрындагыча, авторның төрле шәхси күзәтүләре дә урын алган. Мәсәлән, ул дәвердә яшәгән татар кешесенең чегәннәр хакындагы һәм Дон казакълары турындагы фикерләре, һичшиксез, игътибарга лаек. Дон казакъларының җитәкчесе Фёдор Шутов турында

«татарча оста ирде» дип, аның татар телен яхшы белүен белдергән юллар да кызыклы.

Монда тасвирланган вакыйгаларга караган, ягъни Оренбург губернасыннан 2000 мишәр һәм башкорт, Казан губернасыннан 1000 татар гаскәриләрен, һәрберсен икешәр ат һәм төзек кораллары белән Украинага җибәрү мәсьәләсендәге рәсми архив документлары фәнни җыентыкларның берсендә басылган*. Ул документларда, ягъни 1756 елның апрель-май айларына караган яшерен хәрби фәрманнарда «яшь егетләр арасыннан иң яхшы, иң тазаларын һәм ышанычлыларын сайлап җибәрергә, Батырша күтәрелеше әле тынып җитмәгәнлектән мишәр старшинасы Яныш Абдуллинны һәм Шәриф Мерәкевне бу походка җибәрмәскә» дигән юллар бар. Шулай ук маршка чыккан гаскәриләр, җирле халыкка зарар китермәсен өчен, мөмкин булганча, торак пунктлардан читтәгерәк трактлардан, далалардан алып барырга тырышырга диелгән.

Әлеге фәрманнар нигезендә хәрби походка җибәрелүчеләр, аларның башлыклары һәм походның барлык чыгымнары турында Мәскәүдәге Россия дәүләт хәрби-тарихи архивында «Наряд о расположении войск на зимние квартиры в удобных местах, а нерегулярных об отлучке в их жилища и о приготовлении провианта и фуража и о протчем» исемле төпләмдә бер документ тапкан идек. Түбәндә тексты басыла торган кулъязмада тасвирланган хәлләргә турыдан-туры бәйле булганлыктан, ул архив документын монда тулаем күчерәбез. Анда болай дип язылган.

«Октября 4 того ж [1]756 году по Указу из Сената требуемая Коллегию сумма ассигнована из отложенного в комиссариате миллиона рублев.

По вышеписанному ж рескрипту наряжено в поход:

– мещеряков – 500, при них старшины: главной – Алкей Муслюмов, помощник Мухаметрахим;

– башкирцов – 500, при них старшины: главной – Кедряс Муллакаев, помощник – Темир Метин;

– казанских татар – 500.

* Материалы по истории Башкирской АССР. Т. IV. Ч. 2. – М: АН СССР, 1956. – С. 491–496.

Которым всем рядовым сукна на кафтаны и шапки по ассигнации от комиссариата отпущены и на них в вышеписанном же, поданном в Сенат доношении требовано сумм денег на год, а именно при мещеряках:

– старшине одному жалованья – 100 ру[блей], на фураж на 8 лошадей – 50 [руб.] 40 [коп.],

– сотников на 5, одному жалованья – 18 [руб.], на провиант – 3 [руб.] 88 [коп.], на фураж на 3 лошади – 18 [руб.] 90 [коп.],

– рядовых на 500, одному жалованья – 12 [руб.], на провиант – 3 [руб.] 88 [коп.], на фураж на 2 лошади – 12 [руб.] 60 [коп.].

А на всех 506 человек: жалованья – 6190 ру[блей], на провиант – 1960 [руб.] 3 [коп.], на фураж – 6444 [руб.] 90 [коп.].

Итого – 14594 ру[блей].

Толикое ж число на башкирцов и казанских татар*.»

Менә бу документта исемнәре аталган старшина Галикәй Мөслим улы белән аның ярдәмчесе Мөхәммәтрәхим кульъязма текстында да телгә алынганнар. Бу Галикәй, ихтимал, 1755 елда дини һәм милли азатлык өчен татар-башкорт күтәрелешен әзерләгән Батыршага яшерен теләктәшлек белдергән зат булгандыр. Әлеге халык күтәрелеше 1755 елда бастырылганнан соң, тоткынлыктагы Батырша патшабикә Елизавета Петровнага күләмле хат-мөрәҗәгатен язган. 1756 елда язылган ул хатта мондый юллар бар: «...Андан соң хәляикълар бахутка атландылар. Артдагы авыллар безнең авылумыздан уздылар. Вә һәм ул йукаруда йад кыйлунган Орыш авылының Галикәй килде вә әйтде: “Әй, хәзрәт! Бәне бахутка язуб, чиру кешеләре өстүнә сутник итделәр, Гәйнәгә бармак мөмкин дәгүл. Әмма хәзрәт, күңелеңезне хуш тотуңыз, бәнем Гәйнәгә бармакымдан пахутка бармакым хушракдыр. Аның өчүн, качан мөселманларның атланмак хәбәре ишетүлсә, бән үз кулум астындакы кешеләрне тиз заман сезнең хәзрәтеңезгә алуб кайтурмын. Бәнүм кулум астында бәнүм әмеремдән чыгар кеше йукдур”, – диде.**» Тарихчы А.П.Чулошников Батыршага теләктәшлек белдергән мишәр сотни-

* РГВИА. – Ф. 20, оп. 1, ед. хр. 581, лл. 245об.–246об.

** Письмо Батырши императрице Елизавете Петровне. Текст. Транскрипция. Перевод на русский язык. Факсимиле / сост. Г.Б.Хусаинов; УНЦ РАН. – Уфа, 1993. – С. 165.

гы «Аликей»ның ул вакытта үз кул астындагы мишәр командасы белән Бөрҗән башкортларына каршы җибәрелгәнлеген язган[*].

Мәгълүмат өчен искәртик, татар шагыйре Габдессәламнең «Меллагол бәете» Җидееллык сугыш вакыйгаларына бәйле. Чөнки Габдессәлам дә шул сугышта катнашкан.

Юлъязма текстының беренчел укылышын «Гасырлар авазы» журналында бастырган идек[**].

Текстка тыныш билгеләре безнең тарафтан өстәлде. Сүзләр танылмаган урыннарга күп нокталар куелды. Кулъязма текстында очрый торган бихисап топонимнарны ачыклау бурычын өстебезгә йөкләмәдек.

---

[*] Чулошников А.П. Восстание 1755 г. в Башкирии. М.–Л.: изд-во АН СССР, 1940. – С. 74–75.

[**] «Язылды бу язу 1756 елда...» // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2002. – № 1/2. – Б. 16–18.

# ЮЛЪЯЗМАНЫҢ ТЕКСТЫ

*// (1б кәгазь)* «[...] вакытда йазылды бу йазу. 1756 йылда, маһы мөхәррәмнең[1] уникенче көнендә[2] чыгыб китдүк [...]дән сәфәргә зарый-гирйан[3] илә, бер Ходайга тәвәккәл кыйлыб, йазылмышда йу[...] дәйү. Ул Олуг Император [ә]гъзам падишаһымыз хәзрәтләренең хезмәтенә тугрылык берлән хезмәт итмәк өчүн. Биш йөз мишәрләр командасы өйүдән чыгыб, өч көн килеб, Уфа кальгасенең астында[4] тордук. Ике җомга сайланыб, ысмутур[5] булыб.

Йәнә андан китүб, килеб кундук Каршинда. Һәм анда теркәлеб, бирүлде ул Рәхимле Падишаһымыз хәзрәтләрендән йарлухаш: йарты йылга ыстаршина Галикәй Мөслим угылына йөз сум акча һәм чикмәнлек кызыл постау. Йәнә памушнык[6] Мөхәммәдрәхим Йосыф угылына алты айга илле сум акча, йәнә бер чикмәнлек кызыл постау. Йәнә биш сутнукгә[7] бирүлде тукузар сум акча йарты йылга, берәр чикмәнлек кызыл постау. Йәнә бирүлде радәвай казакъларга алтушар сум акча. Йәнә Бөгелмә кальгасенә килгәч берәр чикмән[-лек] яшел постау бирүлде.

Йәнә ул Каршиндан китүб, баруб кундук Олы Арамада. Шунда йасалды йегерме биш кешегә бер капрал.

Йәнә андан китүб, килүб кундук Торнада.

Йәнә анда килүб кундук Үсән суы буйында.

Йәнә андан килүб кундук Чалмалы авылында.

Йәнә андан килүб кундук Ракъ буенда, Исмәгыйль авылында.

Йәнә андан килүб Япрак авылында.

---

[1] *маһы мөхәррәм* – мөхәррәм ае.
[2] *мөхәррәмнең уникенче көне* – григориан ел исәбе белән 7 октябрьгә туры килә.
[3] *зарый-гирьян* – елап.
[4] кулъязмада бу сүз «астанда» дип язылган.
[5] *ысмутур* – смотр.
[6] *памушнык* – помощник, ярдәмче.
[7] *сутнук* – сотник.

Йәнә анда яңа юлга чыгыб, Сүәккүз Мортаза авылында.

Йәнә андан килүб кундук Бөгелмә кальгасендә. *// (2а кәгазь)* Шунда бирүлде фураш вә һәм казакъларга яшел чикмән.

Вә йәнә андан чыгыб, баруб кундук Карабаш авылында.

Вә йәнә андан килүб кундык Актимер башы Зәй буенда.

Вә йәнә андан килүб кундук Куак авылында [...отста]внай солдатларда.

Вә йәнә андин чыктук Чирмешән буена. Мувалны чыгыб, Тимуш Таулы авылында.

Вә йәнә кундук Аднадвур[8] дигән керәшен авылында.

Вә йәнә кундук Казан өйәзенең Зубау[9] авылында.

Йәнә кундук Липовка авылында вә һәм шунда күрдүк чыган[10] халкыны. Кыш көне торалар азбаларда вә һәм ындурларда. Әмма булмас ирмеш анларга тормаклыкга бойурук. Указ берлән булган анларга авыллар арасында көн күрәргә, халяикъларны алдаганлыклары өчүн. Вә һәм ул чыган халяикы шундай зишт[11] мәлгунь кяферләрдер, тәнләре һәм күм-күк, тимер дик кап-кара, телләре һәм башка, мисле диванә[12] ки димәк булмас.

Йәнә андан килүб кундук Часнаковка авылына.

Йәнә андан килүб кунду[к] Кондырча дигән суның буйында Уралуны чыгуб, Ыстарапулский[13] өйәзендә.

Андан баруб кундук Кызылъяр кальгасендә аставнай солдатлар авылында.

Андан баруб йитдүк Самар кальгасенә. Тордык ул кальгадә өч җомга кадәре, Вулгу[14] суыны чыгалмайунча. Көз көне ирде, сил[15] каты акты. Әмма ул Самар халяикы бай халяикъ булур ирмеш.

Вә йәнә андан чыгыб, Барковка авылында тордук бер җомга. Солы, печән фираван[16] ирде. Әмма үзләре мукшы керәшенләре ирде.

---

[8] *Аднадвур* – Однодвор булса кирәк.
[9] *Зубау* – дөресе «Зубовка».
[10] *чыган* – чегән.
[11] *зишт* – ямьсез.
[12] *мисле диванә* – дивана кебек.
[13] *Ыстарапулский* – Ставропольский.
[14] *Вулгу* – Идел.
[15] *сил* – ташкын.
[16] *фираван* – күп.

Вә йәнә ул Барковoвка авылында торган вакытда Дәвеш авылының Рәхмәтулла Йумаш угылы, Габделмәннан Сәет угылы, Әхмәр Йуныс угылы – өчүсе бер төнлә торуб, бер мукшы керәшененең бары бер сарыгун алуб суйганлар ирмеш. Ул кичә Әбүбәкер Гали угылы, Йагкуб Асыл угылы – икесе часавуй ирде. Анларның ут якган йиренә илтүб тунаганлар ирмеш. Вә һәм итләр[ене ...] азбарга күмгәнләр иркән. Иртәгү көн мукшы [...] *// (2б кәгазь)* вә һәм тиресене үзенә бирдүк, ите өчүн [...] акча бирүб, аш [...].

Вә йәнә Самар кальгасендә чыгалмай калган [...] чыктук [...] боз өстүндән акурунлык берлән. Әмма анда [...]

[...] кундук Монастырьский өйәзендә астав[най ...]зовка авылында.

Вә йәнә кундук Балка авылында.

Вә йәнә кундук [...]ский авылында.

Андан Сембер өйәзенә [...] Микулайскийда.

Вә йәнә кундук Топорин авылында.

Вә йәнә кундук Аранский авылында.

[...] Акмәтъяр авылында [...] татарларда.

Йәнә кундук Йалгашлы авылында, мишәрләрдә, бик хөрмәт кыйлдылар.

Вә йәнә андин белдүк [...]

Вә йәнә кундык Арта[17] Әләзәндә.

[...] мукшы авылына вә һәм көнләдек.

Вә йәнә төнләдек Каменка [...] Муловка авылында.

Андан бардук Тамбу[18] өйәзенә.

[...] Мелищев авылында татарларда.

[...] *// (3а кәгазь)* Арупка авылында вә һәм төнләдек [...]ский өйәзенә.

Йәнә кундук [...] Чернов [...] өйәзенә, Раквусы авылына.

Йәнә кундук Казача авылында.

Аннан [...]шкатинский өйәзенә, Ломович авылына.

Йәнә кундук Бурдина авылында.

[...] бардук Ливинский өйәзенә, Русхавич авылына.

---

[17] *Арта* – кулъязмада шулай; дөресе «Урта» булса кирәк.
[18] *Тамбу* – Тамбов.

Йәнә кундык Астарый[19] Сивцов (?) [...]

Йәнә кундук Курумский өйәзендә Букравы [Покравы, Покров-?] авылында. Кальга йанында көнләдек.

Йәнә кундук Чернис [Чернец-?] авылында вә һәм көнләдүк. Ул Курумский кальгасе бик төзек кальгадер, дивары бик йахшы, бик рухмиздүр[20], әмма күп йирне йөрүдүк. Ул кальгадәге өч сүзне [...] күрмәдек.

Йәнә кундук Чаблыслович авылында, аралаш чиркәс [...]

Андан бардук Ахулухав өйәзенә, чиркәс халкына.

Йәнә кундык село Нишозер[...]

Йәнә кундук Ивановкада.

Йәнә кундук село Дуровда вә һәм көнләдүк.

Андан бардук [...] вә һәм Малай Руси дирләр. Вә йәнә күрдүк шул чиркәс [...]туб тартадур йил берлән. Бер арка өстенә ясаганнар димәк булмас. Һәм үзе [...]

Андан бардук Путибелский[21] кальгасене үтә чыгуб, Пусчикан авылында [...] кундук. Канатуб[22] кальгасендә, чиркәс кальгаседүр һәм һәр йылка өч җөз бүлүк. Һәр икүче ун кылнатур.

Һәм ул чиркәс йорты бер олы йорт һәм байлар булур вә һәм кальгасе күб булур димәк булмас.

Һәр йыл өч җөзлык булур һәм ашлукы вә һәм тәмәкүсе бик чүннек [...] йалан һәм төрле мәхлук анда пешәр.

Йәнә кундук Пужук авылында. Андан соң командадан айырулуб, йаңулуш[23] башка йакка, Даграловиич кальгасен буталчук баруб кундук Итук дигән авылында.

Йәнә андан да коруб [...] *// (3б кәгазь)* ике чакрым йир килеп, командага кушулуб кундук. Новый Милин [...] Новый Милни дигән олу кальгадер. Ул кальгадә кышлайдур ирде Дон казакълары, Андрей Дьячкин полкы. Әмма ул Дон халкы бик ат өсте халяикъ [...] һәм төзекләр болай димәк булмас. Һәм безнең барча казакъ командаларына баш булды Донский бригадир гренадер (?) [...] Шутов Фё-

---

[19] *Астарый* – дөресе «Старый» булырга тиеш.
[20] *рухмиз* – ?
[21] *Путибелский* – Путивль.
[22] *Канатуб* – Конотоп.
[23] *йаңулуш* – ялгыш.

дор Иваныч. Бик дә [...] кешедүр һәм йагълу[24] батурлыкы бар ирде, вә һәм татарча оста ирде, үзләре [...].

Йәнә андан китүб баруб кундук Сосынча[25] дигән кальгадә. Ул кальгадә тордук кышларга фатир бирелгүнчә. Чиркәс халкындан Черниговский полк да йәнә бер йакга китүб кышлады [...]

Ыстаршина Галикәй Мөслим угылы өч сутнә башына һәм Мөслим угылы Габдессәлам Аскар берлә безнең ике сутнә менә дигән кальгадә безнең ике сутнә, кышлады. Памушнык Мөхәммәдрәхим Йосыф угылы сутнук вә [...]ккол берлән Киселавка[26] дигә[н] авылында кышладык.

[...] ун йитенче көне ирде, хут йолдузының[27] унбишенче көне ирде, дүшәнбә көн [...]вида һәм [...] авыл әүвәлдә бер җомга кадәр, андан сутник [...] Березна дигән кальгагә. Ул өйәзендә [...]».

---

[24] *йагълу* – яулы, ягъни сугышчан.
[25] *Сосынча* – Сосница.
[26] *Киселавка* – Киселёвка.
[27] *хут йолдызы* – февраль.



*Кулъязманың факсимилесе. 1б кәгазь.*



*2а кәгазь.*



*2б кәгазь.*



*За кәгазь.*



*3б кәгазь.*

## КЫРЫМ СӘЯХӘТНАМӘСЕ

Бу сәяхәтнамәнең авторы – совет чорында эш эзләп Кырымга барган Гобәйдулла Рәхмәтулла улы. Ул 1868 елда хәзерге Татарстанның Кукмара районына керә торган Төркәш авылында туган һәм шунда гомер кичергән тирән гыйлемле кызыклы шәхес булган. Гобәйдулла Рәхмәтулла улы репрессия-сөрелүләрдән имин калган, 1930 елларда Төркәш авылы тарихын язган һәм авылдашларының нәсел шәҗәрәләрен төзегән.

Гобәйдулла Рәхмәтулла улының «Кырым сәяхәтнамәсе»ннән (бу шартлы исем безнең тарафтан куелды) күренгәнчә, ул җитмеш яшькә җитеп килүенә карамастан, 1937 елның май аенда авылдашлары белән Кырымга барган һәм бер ел ярым дәвамында шунда эшләп йөргән. Өлкән яшьтәге диндар бер татар картын яшәгән урыныннан кузгатып, ерак диңгез буйларына икмәк эзләп китәргә нәрсә мәҗбүр иткәндер? Ул хакта автор язмаган. Күрәсең, анда вакытлыча эшкә планлы рәвештә, вербовка буенча киткәннәрдер. Автор күргән-кичергәннәрен, сәяхәтнамә жанрына хас булганча, түкми-чәчми кәгазьгә теркәп калдырган. Ул үзе эшләгән совхозның һәм андагы шәхси хуҗалык эшләрен җентекләп язып барган. Кырымда эшләгән якташларның андагы яшәеше, төрле хәл-әхвәлләр эчендә үзара мөнәсәбәт һәм мөгамәләләре дә чагылган. Анда яшәгән кырым татарлары, караимнәр, немецлар, болгарлар, греклар, яһүдләр һәм башкалар турында мәгълүмат теркәгән. Автор һава торышындагы үзгәрешләр, Кырымның климат үзенчәлекләренә дә игътибар биргән. Җиләк-җимешләр һәм яшелчә турында тәфсилләп язган. Уңыш күпме җыелуын, базардагы һәм гомумән бәяләрне теркәгән. Кырымга бару-кайту өчен күпме вакыт һәм акча сарыф ителүе, ничә чакрым юл үтелгәнлеген дә төгәл исәпләгән.

Әлеге сәяхәтнамәнең төп әһәмияте – аның шәхси кысаларда гына калмыйча, идеологик җәһәттән уңга-сулга авышмыйча, Кырым якларындагы ул чор тормыш-көнкүрешен мөмкин кадәр объектив тас-

вирлауда. Гобәйдулла Рәхмәтулла улы Кырымда күргәннәрен бизәмичә, хурламыйча, бары үзе күргәнчә һәм үзе кабул иткәнчә тасвирлаган.

Кырым татар халкының XX гасырдагы ачы язмышы һәммәбезгә дә мәгълүм. Бу сәяхәтнамәдә телгә алынган Солтансарый, Булгак, Азамат, Салтыбай, Орчык, Мәүлет, Тайган, Кортлык, Җимерек, Сәй һәм бүтән татар авылларының хәзерге вакытта күпчелегенең урыннары гына түгел, исемнәре дә җир йөзеннән юкка чыккандыр. Совет чорының раскулачивание, репрессия, мәчетләрне ябу, муллаларны җәберләү кебек рәхимсез күренешләре дә сәяхәтнамәдә чагылыш тапкан. Гобәйдулла карт Кырымның табигатен, кешеләрен, совет хакимиятенең хикмәтләрен, җирле кырым татарларындагы төрле гореф-гадәтләрне (тел үзенчәлекләре, кием-салым, сәламләшү, өйләнү тәртипләре, тәмәке тарту һ.б.), дингә мөнәсәбәтләрен, Исмәгыйль Гаспринскийга бәйләп мәгърифәт тарихын, латин язуыннан кириллицага күчүне һәм башка төрле вак вә эре вакыйгаларны язып калдырган. Аның Кырым татарларының «сөйләшү телләренә килсәк, безнең Казан татарчасына 25 процент кына туры килә» дигән фикере дә кызыклы. Автор татар һәм кырымтатар мәкаль-әйтемнәрен кулланып язган, аларга аңлатмалар да биргән.

Сәяхәтнамә текстының шактый өлеше безнең тарафтан матбугатка әзерләнеп, беренче мәртәбә 1997 елда Кукмара районы газетасында басылып чыккан иде[*]. Аннан соң Чаллы каласында нәшер ителүче «Мәйдан» журналында 2003 елда дөнья күрде[**].

***

Бу җыентыкта сәяхәтнамәнең тексты тулысынча, үзгәрешсез бастырылды.

Автор текстында төрле мәгълүматлар аралашып, урыны-урыны белән үзара буталыбрак та язылган, шуңа күрә андый урыннарны йолдызчыклар куеп аердык. Текстка тыныш билгеләре дә безнең тарафтан өстәлде.

---

[*] Сагындыра иде Кукмара... // Хезмәт даны (Кукмара). – 1997. – 25, 29 гыйнвар; 5 февраль.

[**] Гобәйдулла Рәхмәтулла улы. Кырым сәяхәтнамәсе // Мәйдан. –2003. – №1. – Б. 106–114.

## СӘЯХӘТНАМӘНЕҢ ТЕКСТЫ

*// (1а кәгазь)* Мин, Хәдичә ике баласы белән, Бәнат ике баласы белән, Гаян, хатыны, Бикә – ун кеше 37 елны 3 нче майда Кырымга диб өйдән чыгыб китдек.

4 нче майда иртә белән Джанкой ыстансасына 63 сум 67-шәр тиенгә билет алып утырып китдек. Көндез 1 сәгатьдә Казанда булдык.

5 нче майда сәгать 12-дә, көндез, Мәскәүдә булдык. Мәскәүгә бер ыстанса җитмәс[тән] билетләрне канфистировать[1] итделәр.

Шул көнне сәгать төнге 1-дә Курски вокзалындин Кырымга чыгыб китдек.

6 нчы майда иртә белән сәгать 7-дә Орловскида булдык.

Шул көнне көндез бер сәгатьтә Курскида булдык.

Янә шул көнне кич 5 нче сәгатьтә Белгород шәһәрендә булдык. Таулары акбур чыга торган таулар икән, шуның өчен Белгород дип исем куйганлардыр.

8-ендә көндез Харьковка килеб җитдек. Шул көнне Джанкойдан Биек Онларга 3 сум 60 тиен өстәмә билет алдык. Көндез 1 нче сәгатьдә Биек Онларга (ыстанса[2] исеме) килеб төшдек.

Биек Онларда Хәдичәләрне, Бәнатларны, Маһины калдырыб, Габдулла белән Сәй дигән совхозга җәяүләб чыгыб китдек. Сәй совхозы ыстансадан 22 чакрымлар чамасы булырга кирәк диб әйтделәр. Биектән[3] унике чакрымда Кукин дигән почта ыстансасы, җул – телефонлы җул. Дүрт-биш чакрымдан дүрт-биш чакрымга Кырым татарларының авыллары бар, исемләрен язарга хәтергә килмәгән. Бер нимес авылы да бар. Сәйдән 6 чакрым чамасы, Биеккә таба таш юлны ташлаб, Сәйдән килгәндә шул авылга сулга борылыб керәсең. Бу – кайту уңгае Биеккә.

---

[1] *канфистировать* – компостировать.
[2] *ыстанса* – станция.
[3] Ягъни, Биек Оннардан.

*// (1б кәгазь)* Шул көндә, кич, икенде[4] вакытларында, Сәй совхозына барыб җитеб, бер бакча каравылчысында кундык. Кырым татары иде.

Иртәгесен – 9-ында Гаян җанына диб, янә дә җәяүләб, Орчык дигән, Сәй совхозының бер фермасына китдек. Орчык «3 нче ферма» исемендә җөри. Гаян Орчык хуторында булмады, шул хутордан янә дә 12 чакрым чамасы Валачи исемле бер ташландык нимес посёлкасына сарык белән киткән икән. Шунда сарык көтәргә җибәргәннәр. Шул посёлкага Гаян җанына барырга туры килде. Хутордан ат белән шул көнне барып җиттек.

10 нчы майда Гаян хатынын, Хәдичә, Бәнатларны алмага барырга хуторга кайтыб китде. Без шунда Габдулла белән икәүләб Гаян көтүен карадык. Гаян барыб хатынын, башка хатынларны Орчык хуторына алыб кайтды да Хәдичә белән Бәнатны, Бикәне шунда калдырыб, хатынын үзе тора торган Валачига алыб кайтды.

11-ендәмә, 12-ендәмә, Гаян кайткач, үземне яңа туган сарык бәкәйләре[5] карарга алды. Сарыкларның бәкәйләгән вакытлары иде. Мин бер атналык, 15 көнлек бәкәйләрне хутор әйләнәсендә аналары белән аерыб көтәм. Өч атнадин соң, өч атналык бәкәйләрне миндән аерыб алыб, Габдуллага алыб бирә баралар. Минем көтүдә 30-35 баш яңа туган бәкәйле сарыклар була. Габдуллада 3 атнадан югары якдагы, бер айлык, артыграк үскән бәкәйле сарыкларны көтә. Аның көтүендә 60 баш–70 баш сарык була. Габдулла хутордан 0,5 чакрым чамасы. Ул вакыт курмының[6], печәннең үскән вакыты иде.

*// (2а кәгазь)* 14-ендә сарыкларның җонын алдырырга Орчык хуторына кайттык. 3 кич анда куныб, сарыкларның җонын алдырып кайтдык. Сарык җонын алу двигатель белән эшләтеп, машина белән кыркалар. Сарыкларның җонын караб, 1 нче сортка, 2 нче сортка, янә айры җонга – өч сортка аерыб, колакларына билге куялар. Беренче сорт җонлы сарыкның колагына калайдан ясаган билге тагалар, 2 нче сортка тамга салалар, 3 нче сортка, белмимен, хәтеремдә калмаган, нидәй билге куялардыр.

---

[4] *икенде* –төштән соң Кояш баеганчы ике арада укыла торган намаз.
[5] *бәкәй* – сарык бәрәне.
[6] *курмы* – корма, терлекләр өчен печән һәм башка төр азык.




*Кулъязманың 1а кәгазе.*

17-ендә Валачига кайтдык. Арасы 12 чакрым, бер Кырым авылына керми, басудан-басуга кудык. Җул өстендә бер «Мәүлүш совхозы» дигән бер совхоз бар, янә бер кырыйда «Мәүлүт авылы» дигән кырым татарлары авылы бар. Мәүлүт авылы Орчыкка кайтканда уң якта, Салтыбай дигән кырым авылы сул якта кала.

***

Инде Валачи посёлкасыны искә төшерәм. Ул посёлка 15 йә 20 җортдан торган нимес авылы булган. Мал асрап, таштан извис яндырыб, күрше авылларга җорт агартырга извиснең бер потына бер пот бодайга алмаштырыб, баеб ятканнар. Шушы көндә җортларының күбесе җимерелеб, ватылыб беткән. Бүгендә бер нимес дә җук. Үзләре чыгыб качканмы, әллә разкулачивать иткәнләрмә – шуны бригадирлардан сорамаганым. Тик мазаркаларындан[7] нимес посёлкасы икәнен белеб була, кечерәк кенә мазарка, аркылылы тимерләр чыгыб җаталар.

Посёлкада бик яхшы бер кое бар. Өч мең сарыкны һәр көнне шунда суаралар[8]. Суы бик мул, су бетми. Ат белән әйләндереб бер кеше ат куа, бер кеше кисмәкне шанга[9] *// (2б кәгазь)* аудара. Мал асраганлыклары галәмәте – һәр пуҗым[10] артында өч гектар яки артыграк урынны таш койма белән әйләндереб алганлар, мал җабу өчен булырга кирәк. Койма урыннары билгеле. Совет власте булгач ташларын извис яндырырга ташыганлар, һаман да яндырыб яталар. Утын урынына җир күмере ягалар. Җир күмерен ыстансалардан автобузлар ташыб торалар.

18 нче майда Хәдичә белән Бәнат безгә килеб китделәр. 20 нче майда, сарыкларга укол салдырырга диб, Валачидан икенде вакытында чыгыб китдек Орчыкка. Габдулла Михаил белән кушыб алып китде. Габдулланың бәкәйләре шактай исәйгән иде. Минем бәкәйләр бар да атналык да 15 көнлек – яшьләр, миңа аерым куарга туры килде. Габдуллалар бик асат[11] кудылар да, мине ташлаб китде-

---

[7] *мазарка* – дөресе «мазанка», ягъни балчык белән сылап агартылган өй мәгънәсендә булса кирәк.
[8] *суаралар* – сугаралар.
[9] *шан* – чан, ягъни бик зур кисмәк.
[10] *пуҗым* – русча «поземь» сүзеннән, хуҗалык һәм йорт урыны.
[11] *асат* – ансат.

ләр. Озын печән, вак бәкәй бара алмыйлар, печән арасында яталар. Анда барганда 60 башлаб бәкәй булды. Әле бер кырыйга, әле икенче кырыйга, әрле-бирле куып җөреб, бик ардым. Төн карангы, туктаб торырга мөмкин түгел. Габдуллалар һаман да баралар, туктамыйлар. Бераз карангы төшкәч, миңа иптәшкә бер урыс малае килде, Николай исемле. Ул килеб куышкач кына азрак сулу алдым. Төн буе барыб, таң алдыннан Мәүлүт хуторы янында сарыкларны ял итәргә туктатдык. Берара шунда сарыклар да, үзебез дә йоклаб алдык.

Таң беленү белән // *(3а кәгазь)* янә кузгалыб, Орчык хуторына куа башладык. 21-ендә барыб җитеб, 26 нчы майда эш бетереп чыктык. Сарыкка уколны җилем тирәсенә кадыйлар, бәкәйләргә кадамыйлар.

Кайткач, 28-ендә, 29-ында каты эссе булыб, җирдә яткан тимерне тотыб булмады, кулны яндырды. 30-ында, 31-ендә җил чыгыб, салкынчага әйләнде. 1 нче июньдә иртә белән салкын булды, көтүгә тун киеб чыкдым. Диңгез буе якын булганлык белән һава алмашыныб тора. Евпатория шәһәре 25 чакрым гына диделәр. Евпатория шәһәре диңгез буенда булырга кирәк.

Беренче июньдә Гаянлар җанындан үзебезнең бригадир Цирби фамилияле, шунда күчдек. Һава бер төрле тормый: көндез эсселек 30 градус булса, кич белән журган, тун бөркәнеп ятасың, салкын була. Менә бүген 7 нче июнь һаман да шәфәкъ бата, яктылык калмый.

27 нче июньгәчә бәкәй көтдем. Сарык бәкәйләү 15 нче июньдә бетде. Минем бәкәй зур көтүгә кушарлык булгач, миңа эш бетде, 28-ендә расчут[12] алдым да, Орчыкка кайттым, Хәдичәләр янына.

Гаян беренче июньдә, монда көтү хезмәте авыр диб, расчут алыб чыгыб киткән иде. Ул Симферопольгә тимер юл белә барыб, андан автобуз белә Карасу шәһәренә барган да, Карасубазар шәһәрендән өч чакрым ераклыкта Мәрьян исемле бакча совхозына барыб кергән. Шундан миңа хат языб, килергә чакырды. Ул чакырган хатны алгач, 2 атнадан соң мин, расчут алыб, шунда барырга уйладым.

// *(3б кәгазь)* 30 нчы июньдә Орчык хуторындан Сәй совхозына кибетчегә утырып китдем. Сәйдә Биеккә барырга автобуз туры килмәде. Биеккә җәяү барырга чыкдым. Биеккә 10 чакрым калгач, бер шофёр бодай өстенә утыртыб алыб китте. Аякларым бик талчыккан

[12] *расчут* – расчёт, исәп-хисап ясап эштән китү.

иде. Шофёрга бер сум акча бирдем. Өч сум биргән идем – алмады, «Син карт кеше, арган күк тигәч, кызганыб утыртдым», – диде.

Шул көнне тимер юлга утырыб Симферопольгә китдем, өч сум 60 тиен түләдем. Симферопольгә төшкәч, городской ыстансага[13] барыб, Карасубазарга автобуз билеты сораган идем, кич сәгать 5 иде, ул көнне иртәгә утырасы билет сатылыб беткән булды. Билетны бер көн алдан сатыб куялар икән. Миңа «Дом крестьян»да кереб кунарга туры килде.

Городской ыстанса каршысында өч ятажлы[14] таш җортны «Крестьянский дом» ясаганлар. Анда куну өчен паспортыңы бирәсең дә, өч сум 50 тиен фатир җалы алалар. Багажны аерым ала, аңа 50 тиен түлисең, икенче бүлмәгә принимайт итә[15]. «Дом крестьян» бик зур, алай-болай истинҗага[16] кысталсаң, тиз генә табарлык түгел, алданрак сораб, белешеб куярга туры килә. Һәркемгә бер караватбирәләр.

Иртәгесен билет алырга чыкдым, билетне янә дә иртәгә утырырга саталар. Бик куркыныб китдем, тагы бер кич кунасы була инде диб. Ул арада бер рус: «Князь, кая барырга уйлыйсың?» – диб сорады. Мин: «Карасуга бармакчы идем, кичә билет алырга җитешмәдем, бүген тагы *// (4а кәгазь)* билет алыб, монда кунарга туры килә. Бу автомашинага билет алыб бетергәнләр икән», – дидем. – «Кулда акча бик аз, бик аптыраб китдем әле», – дидем. Ул урыс алдагы көндә ике билет алган икән, берсен кешегә диб. Ул иптәше килмәде. Утырырга машина килде. Шул билетне миңа бер сум файда алыб сатды да, Карасубазарга утырыб китдем.

3 нче июльдә Карасубазарга килеп, андан күтүмкәләрем[17] белән Мәрьян совхозының беренче отделениясенә бардым. Беренче отделениянең управляющие Моратов дигән кырым татары. Казан татарчасын бик яхшы белә. Герман сугышы вакытында Казанда хезмәт иткән, шунда татарчаны бик яхшы өйрәнгән. 4-ендә, 5-ендә ял итеп, 6-ында бакчага каравылга алды.

---

[13] *городской ыстанса* – шәһәр станциясе.
[14] *ятажлы* – этажлы, катлы.
[15] *принимайт итә* – кабул итә.
[16] *истинҗа* – тәһарәт, пакьләнү.
[17] *күтүмкә* – котомка.

7 нче июльдән 1 нче октябрьгәчә бакчада җөрдем, һәр көн 8 сәгать бакча карыйсың. Бакчаның бер кисәге 35 гектар, шуны әйләнеп җөрисең. Мәрьян совхозы барлыгы алты отделениягә бүленгән, алты отделениядәге бакчаның күләме 750 гектар. Бер отделение өчкә бүленгән.

Бакчада һәртөрле агач бар: алты-җиде төрле алма бар, өч төрле груша бар, чия бар, черешник дигән җимеш бар, өрек җимеше бар, кизил дигән җимеш бар, виноград бар, әстерхан чикләвеге, куак чикләвеге бар, масловка, ыслива дигән җимеш агачлары бар. Андан башка ашарга яраксыз җимеш агачлары: тышы тигәнәк күк, эче агач күк каты, аннан башка лимон рәвешендә бер төрле җимеш – аны да ашамыйлар. Андин башка мин исемен белмәгән агачлар да бар. Бер елда гына барын да белеб булмый икән.

*// (4б кәгазь)* Памидур, кәбестә, карбыз утырталар. 1937 елны саткан җимеш-фрукталар йөз мең тоннага тулган. Шуның приходы расходына 8 мең сум тулмаган, чөнки һәр числога 75 мең чамасы акча китә. Расхутка, ягъни рабочийлар жалуаниясенә[18] бу ел аяз булып, вакытсыз алмага корт төшеп, вакытсыз коелды диделәр. Шуның белән фрукта[19] арзан бәһагә сатылды, диделәр.

Бакча җимеше 10 нчы октябрьгә җыелыб бетәргә тиешле булса да, 25 нче октябрьдә генә бетте.

1 нче ноябрьдә бакчадан чыгыб, басуда тракторлар, керосинлар, майлар сакларга кердем. Кич сәгать 5-тә барам, иртә белән сәгать 7-дә кайтам. Бер ай тракторда тордым. 1 нче декабрьдә двор[20] карарга алдылар. Двордагы хезмәт – ишек алдындагы чүбне себерәсе 2 көндә бер мәртәбә, кәнүшни[21] кабка төбен һәр көнне җыярга туры килә. Иртә белән сәгать 7-дә звонок[22] сугасың эшчеләр җыелырга. 8 сәгатьтә эшкә чыгыб китәргә сугасың. Көндез сәгать 12-дә ашарга кайтырга, сәгать 2-дә чыгыб китәргә, янә кич сәгать 5-дә эшдән кайтырга звонок сугыла.

---

[18] *рабочийлар жалуаниясе* – эшчеләр хезмәт хакы.
[19] *фрукта* – җиләк-җимеш.
[20] *двор* – ат фермасы һәм аның тирәсе.
[21] *кәнүшни* – конюшня, ат абзары.
[22] *звонок* – кыңгырау.

Габдулла Валачидан расчут алыб, минем җанга 7 нче августда гына килде. Хәдичәләр, Бәнатлар, Бикәләр Габдулла белән килмәде. Орчык хуторында калганлар. Алар анда иген эшендә эшләделәр. Бәнат шунда кияүгә барды. Бикә безнең янга ноябрьдә килде, дунгыз карарга керде.

***

Ноябрьнең 6-ында, җомга көн, рузәгә[23] кердек. Кырым татарларының хатынлары рузә тота, ирләре тотмый. Рабочий кырым татарлары семьялеләре[24] ун семья бар. Башка рабочий украин халкы күбрәк: *// (5а кәгазь)* семьясез хатын-кыз, семьясез ирләр.

25 декабрьдә ике биршук[25] кар яуды. 2 көн торыб, эреб бетде, сулар ташыды. 30-ында янә 2 биршук яуды, 3 нче гыйнварда эреб бетде. Аяк асты саз, туң җук.

6 нчы гыйнварда чиратды[26], буранлап явып, 7 биршук кар булды, 7-8 градус суык булды. 8-9-ында көн начар, 10-ында аяз, кояшлы, тамчы тама. 11-ендә кар эреб бетде, җиргә таянды, кайда басма – анда су булды бу.

***

Габдулла 7 нче агустда минем җанга килеб, коелган алма җыярга керещде. Алма җыю вакыты иде. Алма җыю нормасы алты яшшек[27] – өч сум сиксән тиен бәһа иде. Габдулла 9 яшшек, 10 яшшек җыеб барды. 17 көн эшләде. 2 нче сентябрьдә Габдуллага эш бирмәделәр, уку яшендәге бала диб.

Шул сәбәпле Габдулланы Карасубазарга ышкулга[28] укырга бирергә туры килде. Анда бер ай укыды да, беренче ноябрьдә, директордан сораб, өйгә кайтыб китде. 6 нчы ноябрьдә Карасубазардан Симферопольгә автомашинага утыртыб җибәрдем, үзем шунда совхозда калдым. Юлга 100 сум акча биреб җибәрдем.

---

[23] *рузә* – ураза.
[24] *семья* – гаилә.
[25] *биршук* – вершок, 4,4 сантиметрга тәңгәл озынлык үлчәү берәмлеге.
[26] *чирату* – җир өстенең җиңелчә туңуы.
[27] *яшшек* – ящик, тартма.
[28] *ышкул* – мәктәп.

Габдулладан соң декабрьдә бакчадагы җортдан югары убшыжитиягә[29] күчдем. Гаянларга аерым кумыт[30], семьясезләргә аерым кумыт бар. Гаян Михаил белән бер кумытка керделәр. Мин ирләр тора торган 14 караватлы убшыжитиягә кердем. Ул кумытта бары ике татар, ике болгар, калганлары хахуллар[31] булдык. Татардан берсе – мин, берсе – Җулбат малае Әхтәм иде.

Сәй совхозында торганда расхут // *(5б кәгазь)* аз чыкды, анда кибет җук иде. Икмәк алдык да, совхоз ара-тирә ит бирде. Онлай[32] алдык, үзебез пешертеп ашадык. Әртилгә[33] бер кухарка[34] бар иде.

Бу Мәрьян совхозында Баши дигән Кырым авылының отделения[35] кибете бар. Сельпосы Башида, зурайтып товар салган, Мәрьян совхозындагы рабочийның акчасын сыпырып кына тора. Һәр төрле товар, пулный[36] теккән кием бер вакытда да өзелми, һаман да китереб, өстәб кенә торалар. Һәр көн өч центнер 18 пот икмәк кайтыб тора. Көндәгесе көндә бетеб тора. Нормалы түгел, никадәр алсаң да, бирәләр. Монда килгәч Орчыкдагы расхут бер өлеш ярым чыкды. Анда икебезгә 48 сум тотсак, монда килгәч 73–75 сум чыкды.

12 нче гыйнварда кар тәмам бетде. Көннәр җылынды. 13-ендә җылылык совхозда биш градус булса, Ялтада 12 градус, Батумда 14 градус диделәр. Тик таудагы куаклар арасында гына аз-маз кар күренә. Кырым халкы бияләйсез җөри, салкын гадәтчә генә.

Гыйнвар, декабрь получкасын[37] бик начар бирделәр, әллә ничәгә бүлделәр. Декабрь получкасын 25 гыйнварда гына өзделәр. Убшыжитиядә рабочий кимеде, ике бүлмәне бергә җыйдылар. 24 гыйнвар икенче убшага[38] күчдек.

Гаян Карасубазардан 70 сумга бер ат алып кайтып суйды, тиресен 20 сумга сатты. Безгә килосын бер сум 25 тиен белән бирде. Ите

---

[29] *убшыжития* – общежитие, тулай торак.
[30] *кумыт* – комната, бүлмә.
[31] *хахул* – украинлы.
[32] *онлай* – онлата, он белән.
[33] *әртилгә* – ягъни бөтен кешегә (русча «артель» сүзеннән).
[34] *кухарка* – аш пешерүче.
[35] *отделения* – бүлекчә.
[36] *пулный* – бөтен (русча «полный» сүзеннән).
[37] *получка* – хезмәт хакы.
[38] *убша* – тулай торак.

ярыйсы, мае булмады. Көн җылы, итне тозламаенча тотыб булмый. Гаян кладовщикдан[39] кисмәк алыб, итне тозлады. *// (6а кәгазь)* Гаянлар убшидан аерым бүлмәгә күчкәч плитә[40] булмады, ашны яр кыриенда, чыгыб пешерә торган булдылар. 30 сумга примус алганлар иде городдан[41], ул бозык булыб чыкды, аш пешерергә ярамады, төзәтергә янә 5 сум бирделәр. Аның белән дә эшкә кермәде.

Гаян әйләнә-тирәдәге колхозларны, яз көне керергә диб, белешкәләб тора. Түлке[42] хатыны бер дә колхозга керергә риза түгел, каршы тора. Кайсы як өскә чыгар, анысын киләчәк күрсәтер әле.

Агуст[43] ахырында Зыятдинов Әхтәм дигән бер Җулбат егете килеб керде. 2 ел Украинда җөреб, аягына, өстенә бер нәрсә ала алмаган. Җаланаяк, бер күлмәк белән монда килгәч, әкренләб эшләб, өстенә-аягына бер кат алды. Акчасы булса – бүре күк, акчасы бетсә – шүре күк. Акча барында күзенә ни күренсә – шуны ала. Кирәкмә, кирәк түгелмә – уйлаб карамый. Акчасы бетсә, алган нәрсәсен алтыҗиде сум зыян белән комиссионный кибеткә төшереб сата. Бервакыт, ноябрьдә яхшы гына эшләб 250 сум получка алган иде. Каяндыр Карасубазарда бер ире үлгән бай яшь хатын бар диб ишеткән дә, шул марҗаны[44] эзләб табыб, шуңар җортка керде дә, берәр атна шунда, марҗа янына барыб, ул акчасы беткәнче торды да, акчасы беткәч (хатыны кугандырма) кайтыб янә совхозда эшкә керде. Бүген дә безнең янда убшыда тора. Бикәне аласы килә, Бикә бармый, марҗадан калган кеше дип. Әле хәзер пожарныйга[45] керде. Шунда эшләб тора, зарплат[46] 125 сум ала, җитми.

***

*// (6б кәгазь)* Инде бераз Кырым халкы турысында язмак булам. Кырым татарлары бик надан булган булырга охшый. Гаспринский Исмәгыйль мескен, аптыраб, Кырым халкын агарту нияте белән

---

[39] *кладовщик* – склад мөдире.
[40] *плитә* – аш пешерү урыны.
[41] *город* – шәһәр.
[42] *түлке* – только, ләкин.
[43] *агуст* – август.
[44] *марҗа* – рус хатыны.
[45] *пожарный* – янгын сүндерү оешмасы.
[46] *зарплат* – хезмәт хакы (русча «заработная плата» сүзеннән).

ысулы җәдидне, ягъни яңача уку-укытуны эзләб табкан да, шул укуны Кырым халкына кертеб, агартырга уйлаган булырга кирәк. Әле олуграклар, авыл халкы надан. Совет власте кергәч бер төрле яшьләр укырга кереб шактай ачылганлар, күбесе партиягә кергәнләр.

Кырым авылларында мәсҗедләр калмаган диб әйтеб була: һич мәсҗед-манара күренми. Карасубазарда 18 мәчет булган, бүгендә ике манара күренеп тора. Бер мәчет 25 елларда ябылган, калган берсе 37 елны ябылыб, мулласы кулга алынды. Димәк, 18 мәчеттән берәү дә җук. Без барган вакытда, 37 елның язында шул бер мәчетдә укыйлар иде. Җомга намазларында 40–50 карт буладыр иде. Көз көне ябылды.

Кырым халкында сакал-мыек дигән нәрсә җук, һәркайсы ялтыратыб кырыб җөриләр. Базарга барсаң, 8–9 кешедән ары сакаллы кеше очрамый.

Җомгага килгәндә, көн иртәрәк булса, мәчет алдында тезелеб утырыб, папирус тартыб утыралар. Анда бер гаебкә дә саналмый.

Җәй көне хатын-кызы күбесе җаланаяк җөри. Хатын-кыз да тәмәке тарта, хосусан[47], карчыклар күбесе трүпкә[48] белән тарталар.

Кырымның төб халкы ат ите ашамый.

Ирләрдән хатын-кыз качмый. Алар гадәтендә кыз алу бик кыйммәт тора. Җөгертеб чыгару, кызларны урлау гадәте һич юк. Хатын алырга теләүче һәр ике як меңешәр сум расхут тотарга мәҗбүр, шунсыз кыз ала алмый һәм бирә алмый диләр. *// (7а кәгазь)* Кызны килен итеп төшерергә тотынсалар, бер арбага ике-өч ат җигеб, ул атларны киендереб, яулыклар тагыб, биш-алты кеше шул арбага утырыб, кыз белән җегет утырган арба артындин барабан сугыб, музыка-гармун уйнаб, думбыра кагып, кыз җортындан җегет йортына чаклы озата баралар.

Аракы эчү бер төрле – хатын-кызда да, ирләрдә дә гаеб саналмый, эчәләр.

Бер җомгада мулласына кергән идек, намазга иртәрәк иде, исәнлек-саулык сорашкач минем алдыма тәмәке тартмасы, кәгазь, шырпы китереб куйды. Мин тәмәке тартмыймын дигәч, гаҗәбләнеб караб куйды.

---

[47] *хосусан* – бигрәк тә.
[48] *трүпкә* – трубка.

***

Гаян беренче февральдә колхозларга чыгыб керде, һәркайсы колхоз член итеб[49] ала, ләкин совхоздин расчут алыб чыкмый торыб принимайт[50] итмиләр.

Совхозның әйләнә-тирәсе авыллар. Мәрьяннең кояш чыгышы ягында Карагач дигән болгар авылы, 4 чакрым чамасы. Андан кыйблага таба Борча авылы, руслар. Андан янә төшлеккә[51] таба Җимерек авылы, татар (Кырым). Янә төшлекдә Солтансарый авылы, татарлар. Андан кышкы кояш баешына борылгач грек авылы. Андан Кортлык авылы, татарлар. Андан Баши авылы. Янә аның җәйге кояш баешында Тайган авылы. Андан борылыб Карасубазар һәм Азамат авылы.




[49] *член итеб* – әгъза итеп.
[50] *принимайт* – принимать, кабул.
[51] *төшлек* – көньяк.



*Кулъязманың 7а кәгазе.*

***

*// (7б кәгазь)* 16 нчы февральдә полный корал белән ике көндә ике полк солдатлар килеб кундылар. Пушкалар, полевой кухнялар[52], башка кирәк-яраклары – һәркайсы үзләре белән бергә. Маневр ясыйбыз дип сөйләнделәр.

***

Сентябрьдә чумаданымдан куен сәгатеме урладылар. Бер убшыжитиядә өч семья идек: мин Габдулла белән, янә бер украин ирлехатынлы, янә Гаянлар хатыны, кызы белән. Сентябрьдә югалган сәгатьне Гаян фибралның[53] 12-ендә «Карасубазардан сәгать алдым» диб, алыб кайтды. 120 сумга алдым ди. Сәгать алыб кайткач ишетеб, мин, Әхтәм, Шестяков дигән урыс сәгатьне күрергә барсак, ни күз белән күрим, минем сәгатьне төзәтдереб алыб кайткан. Сәгатьнең пружинасы ватык иде. Өсте кабыгында[54] унлык тәңкә кадәр шома урыны бар иде, мин шул шома урынына үз исемемне, әти исемен языб куйган идем пәке очы белән. Сәгатьне алыб карадым да, Әхтәмләргә күрсәтдем, «Менә бу сәгать – минем югалган сәгать, менә тамгасы», – диб, язуны күрсәткәч, Гаян да бик аптыраб китде. Әхтәмләр дә: «Дөрес, бу синең сәгать», – диделәр, Бикә дә күрде. Алты ай вакыт үткәч, инде сәгать онытылды диб исәпләб, сәгатьне төзәттереб алыб кайтды. Ул тамганы, ягъни язуны Гаян күрмәгән булырга кирәк. Чумадандан Гаян, йә кызы, йә хатыны ачыб кына алганлар, чумадан бикле түгел иде, алар сәгать барын беләләр иде.

*// (8а кәгазь)* Шундан соң ике арабыз бозылды. Сәгатьне сатыб алмаган, аны чумадандан урлаганларын һәркем ишетде, картның сәгатен Зыятдинов урлаган диб исем чыкды. Мин аны дәгъваламадым, шул көе бер-ике ай торды.

Безнең арада Кыртүкәй исемле, кәнсәләр[55], кибетләр, клублар каравыллый торган бер кырым татары бар иде. Ул бер көнне политотдел[56] Рәҗәпевкә шуны сөйләгән. Политотдел шундан мине чакы-

---

[52] *полевой кухня* – кыр кухнясы.
[53] *фибрал* – февраль.
[54] *өсте кабыгы* – өске капкачы.
[55] *кәнсәләр* – канцелярия.
[56] *политотдел* – сәяси бүлек башлыгы.

рыб, миндән сәгатьнең ни рәвешдә югалганын, билгесен сораб языб алды да (мин аны нәрсәгә язганын да белмәдем), шул арада Гаянны сәгате белән чакырыб, сәгатьне караб, Гаянга: «Сәгатьне картка бир, ату[57] мин сине судка куям, диб куркыткан. Шул ук арада, мин дворда идем, Гаян сәгатьне китереб гуаһлар[58] белән миңа биреб китде. Сәгатьне биргәнче Бикә артындин «сәгать төзәтдергәнгә 15 сум бирәм, сәгатьне бирсә» диб әйттергән идем. Гаян «сәгате кирәк булса, 120 сум бирсен дә алсын» диб ишетдерде. Политотдел бер тиенсез алыб бирде. Шуның сәбәбле Гаян үзенең авторитын[59] югалганын белеб, агустның унысында совхоздин расчут алыб, колхозга керәм диб чыгыб китте. Һәркем «Сәгать урлаган» диб сөйләшкәч, чыдай алмады.

Июньнең 5-ендә Гаян тутасы Шәмсекамал кызы белән килде. Килгәч бик тәбәлдерекләб[60] каршы алган иде. *// (8б кәгазь)* Унбиш кенә көн тордылар, Шәмсекамал, акчалары, муен баулары җугалыб, Гаян белән аралары бозылды. Икесе бер кумытда торалар иде. Җугалган нәрсәләрен Гаянлардан күрде. Шәмсекамалны даулашыб кумытындан чыгарды, үпкәләшделәр.

***

Башда барган Орчык совхозы тирәсен язам. Сәй совхозы Биек Онлар дигән тимер юл ыстансасына 22 чакрым чамасы кояш баешында. Сәй совхозыннан Орчык хуторы 12 чакрым диделәр. Орчыктан ун чакрым Валачи посёлкәсе, һаман да җәйге кояш баешына таба бара. Валачидан уң якта Фрайдер дигән районлы авыл.

Кояш чыгышы Бакуразвизды дигән нимес[61] авылы бар. Бодай, мамык, солы, кукуруз, карбыз, кавын, арпа чәчәләр. Колхоз арыш чәчми, совхоз арыш чәчәләр. Арышны серкәгә утыргач, печәнгә чабыб өяләр малга ашатырга.

Кыйбла тарафында 7 чакрымда Куторка дигән хутор бар һәм авылы да бар, Иске Куторка диләр. Ул Куторкада җуынган таш чыгара-

---

[57] *ату* – а то, югыйсә.
[58] *гуаһ* – шаһит.
[59] *авторит* – авторитет, абруй.
[60] *тәбелдерекләб* – зурлап.
[61] *нимес* – немец.

лар, йомшак таш. Аны стройка[62] өчен, тәрәзә борысларына, ишек борысларына куялар, балчыкдан салган өйгә. Ул ташны бер елга, ике елга мәҗбүри эшкә хөкем ителгән кешеләргә эшләтәләр. Кооперативы бар, ыстоловае[63] бар, һәйбәт, ыстройкалары бик яхшы.

Валачидан кояш чыгышына килсәк, Орчык белә ике арада Салтыбай дигән кырым авылы бар. Юлдан уң якда Мәүлүт дигән кырым татары авылы бар. Орчыктан Сәйгә килгәндә җул өстендә Булгак дигән кырым татары авылы бар, руслар белән катыш. Мәсҗедләре ташдан. Төб татар авылы булса да, колхоз корылгач, эшче кул кирәк диб, килгән русларны да колхозга керткәнләр. Колхозник булмаган кеше җук диб әйтерлек. // *(9а кәгазь)* Чәчкән ашлыклар: бодай, арпа, солы, кукуруз, мамык. Ягарга утын җук, урманның орлыгы да җук, бу тирәдә бакчалар да күренми. Җимеш бакчалары җук. Утын урынына тирес, көнбагыш сабагы җагалар. Җортлар һәркайда бер катлы, балчык кирпечдән салган. Өсте черепис[64] белән ябкан, эче-тышы ак извиз[65] белән агарткан, керсәң – чыгасылар килерлек түгел. Йорты ике бүлем: берсе кухня, берсе ак өй урынына тора. Рәтдән икмәк куярга анбары, шуның белән тоташтан мал җаба торган урыны бар. Койма, капка дигән нәрсә җук. Бу заманда беткән, иске стройкаларда пуҗымны әйләндереб алган таш койма урынлары бар. Аларның да бер заманда әйләндереп алган диб әйтерлек урыны гына калган.

***

Февральнең 25-ендән салкын башланды. Менә бүген 17–18 градус салкын, бер биршук кар яуган иде, тора әле. Кырым халкының бер мәкале бар: «Кырымның кышы – кантардан соң» диләр. Сорасаң, «кантар»ның кай вакытда икәнен, аерыб белмиләр. Тагы да шуңар өстәб әйтәләр: «Февральнең атнасы кала, мартның 10-на кадәрле суык булыр» диләр. «Кантар»лары февральнең соңгы яртысыннан башлана булырга кирәк, март 10-ына кадәрле. Тагы да киләчәкни күрсәтер, исән торсак, Аллаһ теләсә.

---

[62] *стройка* – төзелеш.
[63] *ыстоловай* – столовая, ашханә.
[64] *черепис* – черепица ,чирәп.
[65] *извиз* – известь.

2 нче мартта чиршык[66] килде, көннәр җылы, көндез 12 градус җылы була. Март 13-ендә, 14-ендә һавалар бөтенләй алышынды, яз, җәй мисалы керде. Кырау юк, җирләр кипде, тәбәнәк тауларда кар бетде. 22-ендә, 23-ендә күлмәкчән йөрибез, җылылык 17–18 градус.

***

Кырым халкы арасында очрашканда, кара-каршы «Мераба!» диб әйтәләр, гадәт шул. «Сәлам галәйкем!» диб бик сирәк әйтелә. «Мераба» сүзе һәркемгә гам[67] сүз, һәркем әйтә. *// (9б кәгазь)* «Мераба» дигән сүзләре гарәб халкының «мәрхәба» дигән сүзендән алынган булырга кирәк. Карт-карчыкларга да, хатын-кызларга да исәнлек сораша торган сүз, сәлам урынына җөри.

Хатын-кыз клубка йә собраниегә бармаганда артык чиста йөрми. Чәче алдан, маңлаендан томалаб чыккан була, ябкан шәле муенына төшкән була. Чегән хатыннары күк[68], биленә бер нәрсә – шәльяулык йә башка бер яулык сыман нәрсә бәйләб җөриләр.

Кырым халкы төб берничә сыйныфтан гыйбарәт булырга кирәк. Беренче: мөселман кырым татарлары исемендә җөриләр. Алар шактай күп авылны билиләр. 2 нче: караим дип әйтәләр, яһүдиләрнең бер фиркасе, җәбрәй[69] динендә. 3 нче: кырымчак диләр, ул да яһүди [динендә]. 4 нче: линчә диләр, ул да яһүд динендә. Андан башка болгар, грек бар, болар җирле халык, төб Кырым халкы. Ликин[70] шул кадәресен сорамаганым: Кырым халкы яһүди динен кабул иткәнләрме, әллә җәбрәйләрнең нәселе әүвәлдән шунда була килгәнме? Андан башка нимес, әрмән, рус халкы да бар. Алар килмешәк халык булырга кирәк.

Кырым халкы, гомумән, ирләр, Төркия халкы күк эре, Сираҗи, Гыйльмади шикелле. Ләкин хатын-кыз вак. Мангул пләмәсе[71] булырга охшый. Чисталыклары да җук, шапшак.

---

[66] *чиршык* – сыерчык.
[67] *гам* – хас, гомум.
[68] *күк* – кебек.
[69] *җәбрәй* – еврей, яһүд.
[70] *ликин* – ләкин.
[71] *пләмәсе* – токымы, нәселе.

***

Апрельнең 10-ында өрек чәчәк атды (ак чәчәк), чия яфрак чыгара башлады. Кизил дигән агач туже[72] яфрак чыгарды, җимеше безнең мондагы гөлҗимеш рәвешендә. Көндез һәрвакыт җил була, кич, төнлә җил булмый. 21 апрельдә алма агачы яфрак күрсәтә башлады, дикий ыслива[73] агачы чәчәк атты. *// (10а кәгазь)* Груша, чия, алмагачы 1 нче майга чәчәк чыгардылар. Груша агачы, алпавытлардин утыртыб калганы алты-җиде вершоклы, карама агачы күк җуан һәм ун метр озынлыкта. Ботакларын кисеп борчымаганлар, рәхәтләнеб үскән. 11 груша агачындан алты тонна груша җыйдылар. Хәзерге көндә утырткан груша агачларының җыл саен очларын кисеб тәмам алҗытканнар. 3 метр биеклектән, 4 биршук җуанлыктан уза алмыйлар, йөз агачка бер тонна груша булмый торгандыр.

Кырым халкының янгыр турында бер мәкале бар: «Мартда бака симерсен, апрельдә бер тамлады» (ягъни, март янгырының файдасы җук – никадәр күб булса да, апрельдә яуган янгыр аз булса – файдалы) диләр.

Алма җенесе күб, ягъни күб төрле алма бар. Һәр агачны аерымаерым аумак[74] итеб утырткан. Алдан өлгергән алма «красный шафран», «полосатый шафран» була. Безнең мондагы полосатый, җомшак алма рәвешле түгәрәк була. Андан «розмарин» җитешә. Безнең җүкә алмасы күк ак, 5-се бер кадак[75] килә шафран да розмарин да. Андан «кандиль» дигән җитешә, озынчарак, 2-се бер кадакка бетми, ире[76] була. Соңындан «ыснаб» (синап) җитешә, тәмле була, артык ире булмый.

Груша өч вакытда җитешә, өч төрле: 1 нчесен агуст башына җыеб бетерәләр. Калган икесен сентябрь башында, сентябрь ахырында җыялар. Чия белән өрекне 1 нче июльгә җыеб бетерәләр. Мин 7 нче июльдә бардым, мин барганда өрек, чия җыелыб беткән иде. Нидәй генә фрукта булмасын, пешәр-пешмәсдә җыялар, пешкәнен көтмиләр.

---

[72] *туже* – тоже, шулай ук.
[73] *дикий ыслива* – кыргый слива.
[74] *аумак* – аймак, төркем.
[75] *кадак* – 409,5 граммга тәңгәл авырлык үлчәү берәмлеге.
[76] *ире* – эре.

Виноград октябрьдә җыела, шунсыз тәмле булмый.

38 нче ел өрек чәчәгенә кырау тиде апрель башында, *// (10б кәгазь)* өрек булмады.

Июньнең 6-сында черешник дигән җимеш җитешде, чия рәвешле. Черешник агачы алма агачы рәвешле, 5–6 биршук җуанлыкда. Хәзергә чия агачы 2 ярым биршук җуанлыкда, бер сажин биеклекдә.

***

Март-апрель аенда агач төбенә 6 метрлы брезин[77] җәеб, агач ботагына агачдан ясаган чүкеч белән сугыб, шул брезингә агачдан бер төрле «долгонос» дигән бер чебенне коялар да, шул чебенне бутилкәгә[78] җыеб яндыралар. Ул «долгонос» безнең мондагы урманда агач төбендә, малайлар «керәшен хатыны» диб йөртә торган үрмәкүч рәвешле, тик төсе генә күк. Шул чебен агачка күкәй салыб, шундан корт яралыб, агачны зарарландыра диләр, алманы кортлата диләр.

Андин соң бер төрле чикләвек корты, кара башлы ак корт тәрбияләб үстерәләр. Май аенда шул кортка кәгазьгә күкәй салдыралар. Шул күкәй салган кәгазьне бер кечкенә кабка салыб (кәгазь каб), агач ботагына асалар. Күкәй салган кәгазьнең зурлыгы кругом[79] бер биршук була. Шул күкәйдән корт яралыб, агачка чыгыб, агачка зарарлы кортларны һәлак кыйла имеш. Бу эшкә бер кат агачдан «долгонос» чебенне җыйгандан соң эшлиләр. Андин соң һәрвакыт чәчәк ача башлагач франсусыский[80] зелень, дәхи[81] сабын катыштырыб янә бер төрле мышьяк кушыб кайнатыб, машина белән агачның һәр ботагын җүешләтәләр.

Бакчага махсус специалист[82] – бер җаваплы кеше бар. Мин барында Коршинский дигән кеше иде. Бакчаның яхшылыгын-начарлыгын шул кешегә *// (11а кәгазь)* йөкләгәннәр. Ул 37 ел аяз булыб, алма вакытсыз кортдан зарарланыб, коелды. Коршинскийны, алманы кортлатдың, бакчаны һәлак иттең диб, ноябрьдә гаебләб, ареcто-

---

[77] *брезин* – брезент.
[78] *бутилкә* – бутылка, шешә.
[79] *кругом* – әйләнәсе.
[80] *франсусыский* – французский.
[81] *дәхи* – тагын.
[82] *специалист* – белгеч.

вать итделәр. Төрмәгә керде. Механический цехның директорын, вакытында дару сибәргә машиналарны ремонтдан чыгарып өлгертмәгәнең[83] диб, төрмәгә кертделәр. Андин башка бригадирлардан 4 кеше арестованный[84] булды, бакча тәрбиясендә иҗтиһад кылмагансыз[85] диб. Аты бармаган, тәртәсен кыйнаган дигән күк булды. Һава аяз булыб, алма кортлауда алты кеше гаебле булыб, суд булмаенча, бер ел төрмәдә калдылар.

***

Мәрьян совхозына Кырымдагы стахановчылардан 150 делегат җыелыб, конференция булды, 3 көн дәвам итте. Һәркайсы, бакчачы булса бакчадан, игенче булса игендән бик шәб уңыш алырга сүз биреб, таралыштылар.

Совхозда семья белән торган кешегә бәрәңге утыртырга урын бирелә. Сыер асрарга иркенчелек, җөрергә урыны бар. Сыерларны җыеб бер көтүчегә бирәләр. Тавык, чебеш, каз-үрдәк асрау өчен бик уңгайлы, һәркайда фантал[86] бар. Фантал әйләнәсе күл шикелле су җыелыб ята. Сарык асраучы совхоз көтүенә куша, сарык башына айга 2 сум түли, сыерга айга 5 сум түлиләр. Совхозчы чөгендер утырта, кукуруз чәчә. Чөгендер белән сыер туйдыра, кукуруз белән тавык, чебеш, каз туйдыра. Памидур бик яхшы була. Совхоз памидур, кыяр, кәбестәне эшчеләргә килосын 16 тиен, 20 тиен белән сата. Бәрәңге начар була, килосы базарларда 2 сум – 1 [сум] 80 тиенгә саталар.

***

*// (11б кәгазь)* Корбан бәйрәме үткәч Карасубазарда калдык, бер мәсҗедне яптылар да яслегә алдылар. Мулласын төрмәгә озатдылар. Карасубазардагы унсигезенче мәчет тә бетде. Шактай гына, 60–70 карт җомгага җыела торганлар иде. Инде алар да, җамигъдан сарсылдылар[87].

---

[83] *өлгертмәгәнең* – өлгертмәгәнсең.
[84] *арестованный* – кулга алынучы.
[85] *иҗтиһад кылу* – тырышу.
[86] *фантал* – фонтан.
[87] *сарсылды* – аерылды.

Мәчетләре артындин, урысларның бер гыйбадәт җорты бар иде, аны да алдылар да, көз көне иде, заготзерногa ысклад[88] итделәр, бодай салдылар.

***

28 нче июньдә чия җитешде, черешникны җыеб бетерделәр. Июньнең 10-ындан башлаб эсселек градусы 34 белән 36 арасында булыб, көннең кызган вакыты көндез сәгать 1 белән 3 арасында була.

Верховный Советка Михаэльсон Артур дигән кешене, АССРга[89] Абдарим Шакиров дигән татарны сайладылар.

30 нчы июньдә Әхтәмләргә поверка[90] булып, ике айга уенга[91] алдылар.

1 нче июльдән башлаб эсселек 40–43-кә менде, шактай көнләр дәвам итде.

1 нче ноябрьдән 1 нче майга кадәрле двор хезмәтенә кердем, 125 сум биреб бардылар айлык зарплат. 1 нче майдан 1 нче июньгә зарплатны 85 сумга төшерделәр, һәркөн дүрт мәртәбә ызбанук[92] суга торган идем. Збанукны ыстоловай янына, башка урынга күчерделәр. Збанук сугу айга 35 сум, 40 сум тора икән, збанук сукмаган сәбәпле, жалунияне киметделәр.

***

Беренче июльдә кибетчегә ревизия булып, җиде мең сум суммасы тулмады. Аны чыгарып, Абрам Сәед исемле кырым татарын куйдылар. Кирилл Ибанычны төрмәгә озатдылар. Кирилл Ибанычкә буш яшшекләргә поверка ясаб, хак куйганда *// (12а кәгазь)* булышдым. Шул булышканым өчен диб, миңа бракка чыгарылган 8 коробка конфет, бер кило печенийә вагы, 0,5 кило талканлык оны, 8 йөз грамм кәгазьле конфет бирде. Болар бар да хисабдан чыгарылыб, бракка калган нәрсәләр иде. Үзләре зав. комиссия[93] белән бер пот сыешлы хәлвә яшнегенә тутырыб, конфет, печенийә алыб китделәр.

[88] *заготзерногa ысклад* – ашлык саклау урыны.
[89] Кырым АССРның Югары Советы күздә тотыла.
[90] *поверка* –хәрби-медицина тикшерүе.
[91] *уен* – хәрби өйрәнү.
[92] *ызбанук* – звонок, кыңгырау.
[93] *зав. комиссия* – заведующий комиссией, комиссия мөдире.

***

Июль ае һаман да эссе, аяк астындагы ташлар кыза, басыб булмый. Күб кеше малярия белән җәфаланалар. Өч көндән өч көнгә янгыр.

38 нче ел алма соң җитешде, 10 нчы июльдә бик рәхәтләнеб ашаган идек 37 нче елда. Менә быел һаман да өзеб алыб ашарлык түгел әле, ачы да, вак да. 38 нче ел бакчага каравыл куйганлары җук әле. 37 нче елны 15 нче агустда бакчаның һәркайсы часына[94] каравылчы билгеләб бетергәнләр иде.

1938 елында 10 нчы июльдә двордан кәнүшнигә күчдем. Анда зарплатны артык бирделәр.

20 нче июньдә Симферопольдә собрание[95] булыб, Кырымда латин язуы бетеб, русча язу гына калырга карар чыгардылар. Крымский Исполнительный Комитет[96] 38 нче ел 20 нче июньдә, димәк 1939 елда һәр мәктәптә рус язуы укытылачак булыб калдырдылар.

25 нче июльдә үземә һава сугыб, баш әйләнеб, эч баруы ябышды. 2 көн йөреб, 3 нче көндә тәндәге эсселек 41 градуска менде. Шундан соң мине совхоз директоры Карасубазар больницасына төшәргә язу бирде. Габдулла белән Җәлалетдин хаты килгән иде, күземне ачыб укый алмадым. 31-ендә бераз сихәтләндем. Карасубазар больницасы урын җук диб, ятырга алмады, дару гына бирде. *// (12б кәгазь)* Июль 31-ендә больницада булдым, доктор 4 көн ял бирде. 2 нче агустда яхшы сихәтләндем. 4 агустда эшкә чыкдым.

Гаян 20 нче июльдә расчутка гариза бирде, сыерларын сатарга базарга төшделәр. Тутасы кала. Гаян хатыны туталарының 18 сумлык муен бавын сандыгындан алганлар. Шуның белән хәзер берсе-берсенә эндәшмиләр. Сандыгындан шактай акчасы да югалган. Сандык ачкычы сандык астына куеб җөреткән, «инде ачкычны үз янымда җөртәм» ди. Гаян белән бер кумытда торалар иде, инде аерылышдылар, Шәмсекамал башка кумытка чыкды.

[94] *час* – часть, өлеш.
[95] *собрание* – җыелыш.
[96] *Крымский Исполнительный Комитет* – Кырым Башкарма Комитеты.

***

Кырым халкының хатын-кызлары яланаяк җөри, һәркайсы төтен эчә[97]. Кубшылыкны белмиләр. Яулык япса да, чәче маңлаендан томалап чыгып җөри. Кызлары чәч толымын 14 йә 16 кисәккә үреп җөри, ваклап үрә.

Кош-корт затындин бакчада «сак-сак» дип кычкыра торган кош, тәкәрлек рәвешле, мөгезле кош бар. «Пуп-пуп-пуп» дип тавыш бирә торган төйлегән[98]. Карга жук. Чәүкә бар, грушаны ашый. Җорт күгәрчене бар. Бүре жук. Куян бар, «таушан» диләр.

Сөйләшү телләренә килсәк, безнең Казан татарчасына 25 процент кына туры килә. Үзаралай сөйләшкәндә сүзләрен аңлаб булмый, бозыб сөйлиләр. Фаразан[99], «ашыгыч» дигән сүзе «аҗылады». Күп сүзләре гарәбчәдән бозылган. Язуларында «х» юк, «һ» катышдыралар «х» урынына.

***

Гаяннар 9 нчы агустда расчут алып, колхозга керәбез дип чыгыб китделәр. Бикә дә шуларга ияреб чыгыб китде, 10-ында Карасуга төшеб. Карасудан унсигез чакрымдан // *(13а кәгазь)* ераклыкда Шаукал дигән авылга колхозга кергәнләр. Ул колхозда өч көн [торгач], Гаян хатыны «авырыйм» диб сылтаулаб, колхозда эшләмәс өчен бо[льницага] төшеб, шул төшүдән колхозга кайтмаенча, Мәскәүгә кайтыб киткәнләр. Бикә дә ияреб китде.

Кырым татарлар колхозда дунгыз асрый. Тәрбияләб заданиягә[100] бирә диләр.

15 нче агустда грушаның бер төрлесе җыелыб бетде, «кандиль»-дигән алма җыярга башладылар. Алманың уңышы 36 нчы елга караганда шактай артык диләр. Алманың коелганын 15 агустдан Карасуга, Симферопольгә автобуз белә озаталар. Һәр көн 8–10 автобуз ташыб тора. Җыярга кеше җитешми. Управляющий Моратов ике-өч мәртәбә Мелитопольгә, Ялтага, Сәедләргә кеше вербовать итәргә[101]

---

[97] *төтен эчә* – тәмәке тарта.
[98] *төйлегән* – тилгән.
[99] *фаразан* – мәсәлән.
[100] *заданиягә* – хөкүмәт тарафыннан бирелгән хезмәт бурычы.
[101] *вербовать итү* – туплау.

җөреб кайтды, кеше таба алмады. Барабыз диб вәгъдә куйган кешеләре килмәде. Аның өчен – колхозларда эш сезоны.

Шушы көнләрдә Карасу базарында карбыз, кавын, ыслива, виноград, кабак, бакланҗан бихисаб тулыб ята. Бәрәңге килосы – бер сум, суган – килосы 80 тиен, карбыз – 70 тиен, кавын туже. 50 килолаб саталар. Виноград 1-50 тиен, ыслива 1-20 тиен, алма – бер сум. Безнең ысталовойда: алма – 40 тиен, памидур – 45 тиен. Базарда май – 6 сум, эремчек – 40 тиен, калыбка сугыб ясаган ремчек – сыр диб йөртәләр – килосы 5 сум. Кибетләрдә май жук, йөзем җимеше юк.

Һәр кибет ашамлык нәрсәләре, икмәк, күмәч, печенийә, прәник тулыб ята. Чат саен буфет, аракы, шәраб, башка исертми торган эчемлек күб. Ларёклар атлаган саен диб әйтерлек.

***

*// (13б кәгазь)* [Шу]шы көндә һәр рус кырымча белә. Борын заманда Кырым халкы надан булу сәбәбле, һәр рус татарча белергә мәҗбүр булганлар. Бүгендә Кырым хатыны-кызы да русча шактай beләләр, дөнья аларга да белергә мәҗбүр иткән.

***

Бакча мәсьәләсенә килсәк, 1 нче, 2 нче, 4 нче, 6 нчы отделениянең бакчалары Шешмен дигән яһүди бакчасы булган. 560 гектар урынны тоткан. Центральный кантур[102] шушы беренче отделениядә зур таш җорт. Директор, политотдел, дәхи бер башында малярлар торалар. 2 нче җорт да кантур, касса. Һәммәсе алты отделениянең эшен карыйлар. Бер кумытда 10 өстәл, бер кумытда 6 өстәл. Андан башка плановай кумыт[103], политотдел кумыты, рабочком[104] кумыты, Красный уголок[105] – шушылар бар да бер җортда. Андан башка бер корпусда клуб, кино урыны, туб урыны өчен билгеләнгән.

3 нче, 5 нче отделения Бабич дигән яһүдинеке булган. Зур паровой тегермәне, өч катлы, бодай тарта. Механический цех зур тимер-

[102] *Центральный кантур* – Үзәк контора.
[103] *плановай кумыт* – планлаштыру бүлегенең эш бүлмәсе.
[104] *рабочком* – эшчеләр комитеты.
[105] *Красный уголок* – Кызыл почмак.

челек эшен дә эшли, тракторлар төзәтә, һәр төрле иген машиналарына ремонт ясый, бакчага су сибәргә насослар эшли.

Бакчаның күб өлеше су буйлаб. Уртадан су ага, ике ягы болын. Шәмәк, Тулбай су буе күк киң болын. Шуңар җимеш агачы утырткан. Су ага торган елганың як-ягы өчәр гектар киңлекдә, 12 чакрым, 14 чакрым кадәр озынлык урынны алган. Андан ары бәлки Кырым колхозлары булырга кирәк. Һәр колхозның 20 гектардан 40 гектаргача җимеш бакчасы бар диб үзләре сөйлиләр.

Совхозның игенлек урыны 60 гектар, аңар тары, кукуруз, бодай чәчәләр. *// (14а кәгазь)* Совхоз үзендә кырык баш рабочий ат[106] тота. Һәр отделениянең аерым аты бар. Атлар һәркайсы кара козгын рәвешле симез дә, зурлар да. Совхозның алты тракторы, ике җиңел автомобиле, алты автобузы бар. Больницасы бар, дару акчасыз бирә. Бакчада, кәнсәләрия алдында төрле гөлләр, роза агачлары утыртылган. Төрле балыклар җөрер өчен цементтан коеп ясаган күле бар. Фантал суны һаман атыб тора. Һәр көн шул бакчада полный музик[107] уйныйлар. Һәр өч көндә бер мәртәбә кино була. Яңа директор – Кудрясев дигән, җагымлы гына кеше, артык күб сөйләми, кешегә каты бәрелми.

***

Минем ай ярым збунук сукганга акча бирмәделәр. 60 сум тиешле иде. 2 ай кәнүшни дворын җыйганга да түләмәделәр. Моратов дигән управляющий[108] отпускада иде, аның заместителе[109] Бобров дигән яшь җегет иде. Миңа ул эшләрне ул кушкан иде. Теге карт төлке Моратов бирдермәде. Расхутны киметергә тырышалар. Хәзер дворлар тубыкдан чүп, тирес тулыб ята – күрүче жук. Алай-болай комиссия киләсе булса, живо[110] кунихларны[111] кушыб җыештыралар.

---

[106] *рабочий ат* – эш аты.
[107] *музик* – музыка.
[108] *управляющий* – мөдир.
[109] *заместитель* – урынбасар.
[110] *живо* – тиз генә.
[111] *куних* – конюх, ат карауч.



*Кулъязманың 15а кәгазе.*

***

Совхозның эреле-ваклы 300 баш дунгызы бар. Яз көнендә алтыҗиде килолы дунгыз баласын килосын 4 сумдан саталар, руслар алып тәрбияли. Татарлардан тәрбияләргә алучы юк. Өч-дүрт ай тәрбияләгәч, йә бозау алам, йә куй алам диб, базарга илтеб саталар. Дүрт айдан соң 300 сум кадәр сатылган дунгыз балалары бар. Акча кушыб сыер да алалар.

***

1 нче июльдә Симферопольдән бер Орынбур татары килде, Мостафа исемле. 20 нче елда әрмиядә[112] булып, Кырымны алырга сугышка килгән. *// (14б кәгазь)* Кырым сәвиткә[113] калгач, Акмәсҗеддә калган. Врангель безнең Кара диңездәге бар корабны җыеб Франциягә алыб киткән. Мостафа яхшы гына таза эшче. Табкан акчасын тота белми, шуның белән котайган җире жук. Өч йөз сум алса да, айныкы айга бетеб бара.

***

Кырым халкы, гомумән, ирләр, төрек халкы күк зур гәүдәле, хатын-кыз вак, мангул халкы күк.

***

Совхозның күбрәк эшчесе украин халкы, ирләрдән хатын-кыз күбрәк. Алма сезонында хатын-кыз яхшы эшли – 9 сум, 8 сум ала. 5 сумдан да ким эшләми. Кала халкының фәкыйрь-фокарасы алма вакытында һәр отделениядә эшләб яталар.

Совхоз семьяле кешегә яшь алма агачы арасында яшелчә, бәрәңге утыртырга бакча бирә. Сыерлы кешеләргә туже агач арасындан чабарга печәнлек бирә. Сыер башына бер гектар печәнлек чабалар. Бакчага эшче бәрәңге, фасоль, кукуруз, чөгендер, суган, кабак, кәбестә утырталар. Бер мәртәбә чабыб алган урынны 2 нче мәртәбә дә чабалар. Сентябрьгә кергәч 3 нче мәртәбә чабалар. Урындагы кешеләр гектарына печәнне чабарга 70–80 сум бирәләр, җыюны хуҗа үзе җыя. Гаян бер гектар[га] 60 сум биреб чабтырган иде, китерергә

---

[112] *әрмиядә* – армиядә, хәрби хезмәттә.
[113] *сәвиткә* – Советка, Совет хакимлегенә.

25 сумлаб расхут тотды. Киткәндә бакчасы белән печәнен 30 сумга сатыб китде. Зыянга кермәсә дә, файда итмәгәндер.

Быел алма җыярга кеше җиткерә алмыйлар, аяк асты тулы алма ята.

***

Совхозның ыстоловае бар, 4–5 төрле аш пешерәләр. «Бурша»[114] диб исем биргән шурпалары – пурцысы[115] 30 белән 40 тиен арасында була, сарык ите шулпасы, янә «кәтлит» диб әйтәләр – төйгән ит, перловай ярма[116] боткасы 70–80 тиен була. Янә жареный[117] ит макарон белән кушыб бирәләр – 1 сум йә 90 тиен була. Янә алма кайнатыб, писүк[118] *// (15а кәгазь)* салыб кайнаткан су – «канпут»[119] диләр, ыстаканы 18–19 тиен була. Янә чәй бирәләр, ыстаканы 12 тиен була.

***

8 нче сентябрьдә расчутка заявления[120] бирдем. 26-ында расчут алдым да, Карасубазарга төштем, Симферопольгә барырга дип. Автобузга 7 сум 15 тиен бирдем. 1 сум 40 тиен багажга диб алдылар. Арада Зуя дигән бер ыстансага гына туктый. Ике арасы 45 чакрым диләр Карасу белән Симферополь арасын. Шул арада туксан ике автобуз[121] каршыга узыб китде. Шулкадәр күб җөри, җиңелләре дә күб.

Симферопольгә кич сәгать 6-да төшдем. Багажны камер ахранга[122] бирдем, 80 тиен түләдем. Дүшәнбә көн 26-ында вокзалда кундым.

Сишәнбә көн көндез сәгать 12-дә 67 сум 60 тиен билеткә түләб, Кукмара ыстансасына кайтырга чыгыб китдем.

---

[114] *бурша* – борщ.
[115] *пурцы* – порция.
[116] *перловай* – арпа ярмасы.
[117] *жареный* – кыздырган.
[118] *писүк* – песок, шикәр комы.
[119] *канпут* – компот.
[120] *заявления* – гариза.
[121] *автобуз* – гомумән, автомашиналар күздә тотыла.
[122] *камер ахран* – камера хранения, саклык камерасы.

Симферополь белән Казан арасы 2341 чакрым. Димәк, Кукмара Карасубазарга 2500 чакрым була.

Харьковка чәһаршинбә[123] көндез сәгать 9-да килдем. Симферопольдән чыккач ыстанса Мамут, Трakташ, Перекоп дигән ыстансаларны узгач, Азовский мор[е]ның[124] кырыендан су астында 2 чакрым кадәрле урынга тамба[125] салынган, чуен юл чыгару өчен. Суы бик тирән булмаска кирәк. Диңгез суының кимегән урыныннан кубометрлаб тоз җыеб баралар. Кубометрга салалар да, шундан вагон белән тоз забутына[126] озаталар.

Шул көнне, ягъни чәһаршинбә көн, сәгать 12-дә көндез Белгородка килдек. Белгородны чыккач су буйлаб авыл тезелеб киткән. Чакрым саен авыл. Белгородка җиткәнче һәрбер авылның үзенең җимеш бакчасы бар, үз пуҗымында. Андан бире якка чыксак, җорт әйләнәсендә, бакчада бик сирәк кенә эстип[127] – агач җук, балчыгы – кара тупрак, бодай, арпа чәчә.

*// (15б кәгазь)* Июль-агус айларында 42–44 градуска җылылык җиткән иде. Сентябрьнең 17-нә кадәрле агус ахырыннан 30–34 градус булыб барды. 17-ендән һава алышынды, салкын төшде, һәркем пинҗәк киеб җөри башлады.

Чәһаршинбә көн кич сәгать 3-дә Курскигә килдек. Сәгать ярым торды. Кич андан чыгыб, атнакич иртә 8 сәгатьдә Мәскәүгә килдек. Шул көнне билетларны канфасировать итеб, җомга көн сәгать 2-дә Казанга утырыб киттек.

Мәскәү белән Казан арасын егерме өч сәгать җөри. Шул көнне Кукмарага сәгать 6-да кич төшдем. Симферопольдә 18 сәгать, Мәскәүдә 27 сәгать торырга туры килде. Хасыйле кәлям[128], Карасубазардан Кукмарага кадәрле 2 тәүлек вакытны бушка үткәрдем.

1 нче октябрьдә төнлә өйгә кайтып кердем. Димәк, юлда 6 көн вакыт үтте. Барлыгы Карасубазардан Кукмарага кадәрле ашамак-эчмәк, һәммәсенә түләгән акча 100 сум чыкды. Җортка 76 сум тотылды.

---

[123] *чәһаршинбә* – чәршәмбе.
[124] *Азовский море* – Азов диңгезе.
[125] *тамба* – дамба, күтәртелгән юл.
[126] *забут* – завод.
[127] *эстип* – степь, дала.
[128] *хасыйле кәлям* – кыскасы.

***

Мәскәүне чыккач вак каенлык, ире агач жук, тәртәлек кенә. Җәй көне машинадан[129] ут төшеб, каудан[130] кабыныб, агачлар да, җирнең мамыгы да җанган. Күбрәк урыны торф булган. Аның асты ак балчык, шул балчыкны кабка тутырыб заводка озаталар. Андан ак кирпеч сугалар.

***

Кырымча көн исемнәре:
җомга – җомга,
шинбә – җомга иртәсе,
якшәнбә – базар көн,
дүшәнбә – базар иртәсе,
сиһшәнбә – сали (?) көн,
чәһаршәнбә – чәһаршәнбә,
атна кич – җомга ахшамы.

*// (16а кәгазь)* ... Липелтурияне[131] кырымлар «Кизләү» диб җөртәләр.

---

[129] *машина* – паровоз күздә тотыла.
[130] *каудан* – үткән елдан калган кипкән үлән.
[131] *Липелтурия* – Евпатория.

## [1945 ЕЛГЫ ХАҖ СӘФӘРЕ]

*// (1а кәгазь)* Бу язу Диния Нәзарәтенең башы – мөфти Габдрахман Рәсүлинең дусларына язган хаты.

1945 нче елда, 9 нчы ноябрьдә, хөкүмәтнең рөхсәте белән[1] Мәккәи мөкәррәмәгә[2] сәфәр итү нияте белән шунда барырга хөкүмәтебез шул ярдәмнәрне бирде: билгеләнгән дүрт мең ярым сум акчаны алтынга алмаштырыб җибәрделәр.

9 нчы ноябрьдә сәфәргә чыкдык. Самолёт белән Мәскәүдән Бакуга җиде сәгать бардык, Бакудан Бәгъдадка, Бәгъдад шәһәрендән Кары шәһәренә ике сәгать бардык. Кары шәһәрендән Мисыр шәһәренә ике сәгать бардык. Мисырдан Мәдинәи мөнәүвәрәгә[3] ике сәгать бардык. Мәдинәдән Мәккәи мөкәррәмәгә өч сәгать бардык. Барлыгы 18 сәгать бардык.

Барыб җитеб, шул көнне Мәсҗиде Хәрамга[4] кереб намаз укыдык, безгә йөкләнгән бурычларымызны үтәдек, тәмам итдек. Русия мөселманлары белән мөселманларны таныштырдык. Анда барыб җиткәч егерме икенче ноябрьгә кадәр анда тордык. Пәйгамбәребез Мөхәммәд мостафа салал-лаһы галәйһи вәс-сәлямнең[5] мәсҗидендә һәр көнне биш вакыт намаз җәмәгать белән укыдык. Бер мең илле кеше белән укыдык. Шулай намаз укыб, пәйгамбәребез Мөхәммәд мостафа салал-лаһы галәйһи вәс-сәлямнең йөргән юлларыннан, тоткан ишекләрендән тотыб кереб йөрдек. Шул кадәре халык арасында безнең Русиядән барган мөселманларның өсләремезгә караб егълаштылар.

---

[1] Текстның бу урынында «рөхсәте буенча» дигән сүз дә язылган.

[2] *Мәккәи мөкәррәмә* – Мәккә шәһәре.

[3] *Мәдинәи мөнәүвәрә* – Мәдинә шәһәре.

[4] *Мәсҗиде Хәрам* – Изге мәчет, Кәгъбәтулла.

[5] *мостафа салал-лаһы галәйһи вәс-сәлям* – мостафа, ягъни сайланган, Мөхәммәт пәйгамбәрнең (с.г.в.) күркәм исеме.

Унбишенче ноябрьдә фарыз булган хаҗымызны кыйлдык. Хаҗ кыйлганда үз киемләребезне салыб, акбүзгә чормалып, хаҗ кыйлдык, *// (1б кәгазь)* шәйтанларга өч мәртәбә җидешәр таш аттык. Һәркаюмызга тәүфыйк-һидайәт[6] биреп, дөнья-ахирәт[тә] бәхетле булыб, бакый[7] юлга нурлы иманымызны юлдаш итеб, иманымыздан аермаенчы, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән Мөхәммәд мостафа салал-лаһы галәйһи вәс-сәлямнең шәфагатен[8] насыйб итсен, амин! Бирәхмәтикәи йа, Әрхәмир-рахимин[9].

Вә янә фарзы хаҗны[10] кыйлдык. Шундан соң, пәйгамбәремез салал-лаһы галәйһи вәс-сәлямнең йорты мәсҗиде белән янәшә икән, үзене шунда дәфен кыйлганнар[11] икән. Анда күп сахабәләр дә куелган[12] икән. Пәйгамбәремезнең уң ягында Әбүбәкер сыйддикъ[13] (разый Аллаһы ганһе[14]), Госман (разый Аллаһы), Гали (разый Аллаһы ганһе), Билал (разый Аллаһы ганһе), күп сахабәләр куелган.

Пәйгамбәр галәйһис-сәлямгә зиярәт кыйлганымыз[15] өчен бик зур күреб, Русия хаҗилары булганымызга күрә, Мөхәммәд мостафа салал-лаһы галәйһи вәс-сәлямнең мәсҗидкә керә торган юлы икән – шул юлдан безне дә зиярәт кыйлырга алыб керделәр. Пәйгамбәремез кабере өстен ачыб карый торган пәрдәсе бар икән – шул пәрдәсен ачыб күрсәтделәр. Шул вакытда нур эченә гарык булыб[16] калдык. Пәйгамбәремезнең [кабере] зиннәтле булган зиннәтләр белән кәфенләб куйганлар – балкыб торадыр.

Мин Русиядә утыз миллион халыкка мөфти булыб торуга күрә, пәйгамбәремездән сорадым: «Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән кы-

---

[6] *һидайәт* – туры юлга керү.
[7] *бакый* – мәңгелек.
[8] *шәфагать* – яклау.
[9] *бирәхмәтикәи йа, Әрхәмир-рахимин* – рәхимлеләрдән иң Рәхимленең рәхмәте белән.
[10] *фарзы хаҗ* – хаҗның фарыз гамәлләре.
[11] *дәфен кыйлганнар* – җирләгәннәр.
[12] *сахабәләр дә куелган* – ягъни, Мөхәммәт пәйгамбәрнең фикердәшләре һәм чордашлары да җирләнгән.
[13] *сыйддикъ* – тугърылыклы.
[14] *разый Аллаһы ганһе* – Аллаһ аннан риза булсын.
[15] *зиярәт кыйлганымыз* – каберенә баруыбыз.
[16] *гарык булыб* – күмелеп.

ямәт көнендә минга[17] шәфагать кыйлсаң иде?!» – дидем. – «Үзеңдән калган Кәляме Шәриф[18] беләән вә үзеңдән калган хәдисе шәриф[19] белән гамәл кыйламыз», – диб. Шул вакытта «Инша Аллаһ[20]» диеб аваз булыб, колагыма ишетелгән кебек тоелды. «Әлхәмде ли-Лләһи Раббил-галәмин[21]» диеб әйтдем.

Менә безгә кайту юлы парахут белән булуга күрә, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте булды. Кайтканда Тур Сина[22] шәһәренең падишаһысы безнең Тур Сина[га] төшкәнемезне белеб, безне алыб машиналарга утыртыб, үзләренең тора торган җирләренә алыб барды һәм бик зур кунак итде. Шул ук көнендә безне кәртечкәләргә төшертеб, гәзитләргә бастырыб чыгарды.

Мәккәи мөкәррәмәдән унсигез километр Мәрвә тавына, Мөздәлифә тавы өстенә, тәвә[23] чүккән җиргә зиярәт кыйлдык, *// (4б кәгазь)* Илаһи.

Гомәр Рәсүлуллаһны барыб үтерәм диеб касд кыйлган[24] булган. Чыккан һәм үтерәм диеб касд кыйлыб булгач да, «Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте берлән Гомәрнең күңеленә һидайәт биреб, иман насыйб кыйлдың, безләр һәм Рәсүлуллаһны күрмәенче, аслан[25] ямалык кыйлмаенчы, үзенең берлекеңә, берлекең өчен һәм Хәбибең[26] Мөхәммәд мостафа салал-лаһы галәйһи вәс-сәлямнең хак пәйгамбәр икәненә телләребез берлән икърарымыз[27] бар, күңелемез белән растлыкымыз бар. Лә иләһә иллә Аллаһы Мөхәммәд Рәсүлуллаһ[28]. Хәбибе әкрәмең[29] хөрмәтенә без гасыйларга[30] тәүбә, тәү-

---

[17] *минга* – миңа.
[18] *Кәляме Шәриф* – Изге Коръән.
[19] *хәдисе шәриф* – изге хәдисләр.
[20] *Инша Аллаһ* – Аллаһ теләсә.
[21] *әлхәмде ли-Лләһи Раббил-галәмин* – ике дөньяның Хуҗасына мактаулар булсын.
[22] *Тур Сина* – Синай.
[23] *тәвә* – дөя.
[24] *касд кыйлган* – ниятләгән.
[25] *аслан* – һичбер.
[26] *Хәбиб* – Хәбибуллаһ, Аллаһның сөеклесе.
[27] *икърар* – тану.
[28] *лә иләһә иллә Аллаһы Мөхәммәд Рәсүлуллаһ* – бер Аллаһтан башка илаһи көч юк, Мөхәммәд аның илчесе.
[29] *хәбибе әкрәм* – Аллаһның бик хөрмәтле сөеклесе.
[30] *гасый* – гөнаһлы.

фыйк биреб, һәр дәмдә[31] иманымызны юлдаш кыйлыб, кыямәт көнендә үзеңнең дидарыңны[32], Хәбибе әкрәм Мөхәммәд мостафа салал-лаһы галәйһи вәс-сәлямнең шәфагатен барчамызга насыйб ит?!» диеб, Аллаһы Тәгаләдән рәхмәтендән өмит итеб, Раббым, теләкләремезне кабул кыйл, амин! Йа, Раббил-галәмин!

Раббәна әтмим ләна нурәна вәгъфир ләна иннәкә галә көлли шәйин Кадир[33]?! Раббәна фәгъфир ләна, зөнубәна, иннәкә әнтә Гафурур-Рәхим[34]?!

[Мөфти Габдрахман Рәсүли].

---

[31] *дәм* – сулыш.
[32] *дидар* – нурлы йөз.
[33] *Раббәна әтмим ләна нурәна вәгъфир ләна иннәкә галә көлли шәйин Кадир* – Йа, Раббыбыз Аллаһ, безгә нурыбызны тәмам кыл, гөнаһларыбызны гафу ит. Хакыйкатьтә син бар нәрсәгә кодрәтле.
[34] *Раббәна фәгъфир ләна, зөнубәна, иннәкә әнтә Гафурур-Рәхим* – Йа, Раббыбыз Аллаһ, гөнаһларыбызны ярлыка. Хакыйкатьтә син Гафу итүче, Рәхимле.



بو يازو

1 دينيه نظراتينينگ باشى مفتى عبد الرحمن رسوليننگ دوسلارغه

يازغان خاطى 1945 نچى يلده 9 نچى نويابرده حكومتنينگ رحمتى بلان

رحمتى بو ينيه مكه مكرمه گه سفر ايتو نيه‌ستى بلان شوندا بارغا حكومت

حكومتنه تيز شوند يارده اللرنى بيرده بيلگه له نكز دورت منگ

يارم صوم اقچانى آلتنغا آلماشترب بيردى لار 9 نچى نويابرده

سفرگه چقدق صامولوت بلان مسكاودان باكوغا بيرى سعت

باردق باكودان بحرا ننقا بغرات شهرندان قارى شهه رنينه

ايكى سعت باردق قارى شهه رندن ميصر شهه ر ينه ايكى سعت

باردق ميصردان مدينة منوره گه ايكى سعت باردق مدينه دان

مكه مكرمه گه اوچ سعت باردق بارلى 18 سعت باردق

بارب جيتب شول كننى [illegible]

يلا ننگ بو رجالارمزنى اورته دكهه تمام ايتدك روسيه

مسلمان للرى بلان مسلمانلارنى طانشدرق اندا بارب جيتكاچ

بكرى ايكى نويابرگه قدره انداندرق پيغمبرمز محمد مصطفا

صلى الله عليهى والسلامننگ مسجدنده هركننى بيش واقت

نماز جمعت بلان اوقدق برمنگ ايللى كشى بلان اوقدق شول

نماز اوقب پيغمبرمز محمد مصطفا صلى الله عليهى والسلامننگ

يرگان يولدلارندان توشقان ايشكلارندان توتب كرب يردك

شول قدره ره حالق آرا سندا برننگ روسيه دان بارغان

مسلمانلارننگ اسله رمزگه قاراب يغلاشديلار اوبشلى

نويابرده فارض بولغان حاجمزنى قيلدق حاج قيلغاندا

اوزكيسم للرمزنى [illegible] بوزگه چرماب حاج قيلدق

ТАТАРСТАН [illegible]
КУЛЬЯЗМАЛАР
ҺӘМ СИРӘК КИТАПЛАР БҮЛЕГЕ
НАЦИОНАЛЬНАЯ БИБЛИОТЕКА РТ
1012 т.

*Кулъязманың факсимилесе. 1а кәгазь.*

شيطانلارغا اوچ مرتبه جيبرى شهر طاشى آتدق هم فايدوزغا
نه وفيق ميسر ايتب بيرب دنيا آخيرت بختلى بولب باقى بولغا نورى
ايمانمزنى يولداش ايتب ايمانمزدان آيرمايچى الله تعالى نينگ
رحمتى بلان محمد مصطفى صلى الله عليهى والسلام نينگ شفاعتنا نا صيب
ايتسون آمين برحمتيكه يا ارحم الراحمين وينه فارض فاجنى قيلدق
شوندان صونگ پيغمبرمز صلى الله عليهى والسلام نينگ يورتى مسجد
بلان يانا شه ايكان اوزى شوندا دفن قيلغان لار ايكان آندا كوب صحابه
لارده قويلغان ايكان پيغمبرمز نينگ اونگ يا غندا ابو بكر صديق راضى الله
عنه عثمان راضى الله على راضى الله عنه بيلال راضى الله عنه كوب
صحابه لار قويلغان پيغمبر عليهى السلام گه زيارت قيلغان مز آچق
بيك زور كورب روسيه غا چيقلارى بولغانمزغا كوره محمد مصطفى صلى الله
عليهى والسلام نينگ قبرگه كيره تورغان يولى ايكانه شول بولدان
بزغاده زيارات قيلدرغا آلب كردى لار پيغمبرمز قبرى اوستن آچب
قارى تورغان پرده سى بار ايكان شول پرده سن آچب ~~قارى تورغان~~
آچب كورسه تره لار شول واقتدا نور اچينه غارق بولب قالدق
پيغمبرمز نينگ زينتلى بولغان زينت لار بلان كفنلاب قويغان لار
بالقب تراد رهمين وروسيه ده اوتز ميليون عالتقا سيتى بولب تروغا كوره
پيغمبرمزدان سرادم الله تعالى نينگ رحمتى بلان قيامت كننده
مينگا شفاعت قيلسانگ ايدى ديدم اوزنگدان قالغان كلام شريف بلان
داوزنگدان قالغان حديث شريف بلان عمل قيلامز ديب شول واقت~~دا~~
~~شفاعت~~ انشاء الله ديب اواز بولب قلاغيمه ايشتلگان كبك طيولده
الحمد لله رب العالمين ديب ايتدم منه بزگه قايتو يولى باراحوت بلان
بولدوغا كوره الله تعالى نينگ رحمتى بولدى قايتقاندره تورسينه شه هرينينگ
پادشاهسى بزنينگ طوريننا توشگانمزنى بلب بزنى آلب ماشينالارغا
اوترتب اوزلارينينگ تراترغان جيرلارينه آلب باردى هم بيك ضور
قوناق ايتدى شولوق كيننده بزنى كارتچكه لارگه توشرتب گازيت لارگه
باسترب چيقاردى مكه مكرمه دن ~~سيگز~~ اون سيگز كيلامتر مروه طاوينه
بارب زيارات قيلدق

*1б кәгазь.*


صونغدلفا
مزوه طاوی اُستنه ته وه چوکنکان جیرگه ضیارت قیلرق الهی
عومر رسول الله نی بارب اوشروم دیب قصیده قیلغان بولغان چقتا
هم اوتروم دیب قصیده قیلب بولغاچده الله تعالی ننگ رحمتی برلان
عومر ننگ کونگلینه هیدایت بیرب ایمان نا صیب قیلرنگ بزلار هم
رسول الله نی کورمه یلگی آجلا یماغلق قیلماینی اوز ننگ بر لیکنکه
برلیکنگ اُچن هم حبیب ننگ محمد مصطفا، صلی الله علیهی و السلام ننگ
حق پیغمبر ایکانینه تللاربز برلان ایقرار مزبار کونگلمز بلان
راستلقمز بار لا اله الا الله محمد رسول الله حبیبه اکرمننگ
حرمه تنه بز عاصی للر دعا ته وبه ته وفیق بیرب هر دمده
ایماننمزنی یولداش قیلب قیامت کننده اوزننگ دیدارنگنی
حبیب اکروم محمد مصطفا صلی الله علیهی والسلامننگ شفاعتنی
بارچه مزغا ناصیب ایت دیب الله تعالی دان
رحمه تیران اُمیت ایتب ربیم مله‌ک للرمزنی
قابول قیل آمین یارب العالمین
ربنا اتمم لنا نورنا واغفر لنا اینکه علی کل شیئ قدیر
ربنا فغفر لنا ذنوبنا اینکه انت غفور الرحیم
ما شا الله شهید الله سمیع الله حسب الله
الله

ТАТАРСТАН МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕ
КУЛЪЯЗМАЛАР
ҺӘМ СИРӘК КИТАПЛАР БҮЛЕГЕ
НАЦИОНАЛЬНАЯ БИБЛИОТЕКА РТ
ОТДЕЛ РУКОПИСЕЙ И РЕДКИХ КНИГ

1012 т.

*4б кәгазь.*

## [1953 ЕЛГЫ ХАЖ СӘФӘРЕ]

*// (1а кәгазь)* Бисмиллаһи рахмани рахим[1].

Аллаһы Хакъ Сөбханә вә Тәгалә[2] фазыл вә гыйнайәте[3] насыйб кылды.

Хөкүмәтебез Совет властенең рөхсәте белән 1953 елда 14 нче агустда, таңда сәгать 3-дә хаж сәфәренә ният идеб, 18 кеше договор белән алган самолётка утырыб, хаж сәфәренә юлга чыкдык.

Хаж сәфәрендә юлдашларымыз:

Беренче – мөфти хәзрәт Шакир Хәялетдинов, Уфа шәһәре;

2) казый Ярулла хәзрәт Йосыпов, Пенза имамы;

3) Исмәгыйль Мөштәриев[4], Казан имамы;

4) Исмәгыйль Рәхмәтуллин, Мәскәү имамы;

5) Габделбарый Юнысов, Ишанбай имамы;

6) Габделбарый Исаев, Уфа зиярәт мәсҗид имамы;

7) казый Зыяэддин ишан Бабаханов, Ташкиндән[5];

8) Фазылхуҗа Садыйкхуҗа угылы, Ташкиндән;

9) Сакран Гыйльманов, Алмададан[6];

10) Габделхафиз Исмәгыйлев, Ташкиндән;

11) Исмәгыйль Сатаев, Әндижандан;

*// (1б кәгазь)* 12) Минһаҗеддин карый Габдулла угылы, Ташкиндән;

13) Габдеррәхим Мөхәммәд угылы, Төркмәнстандан;

14) Габделбарый Сабир угылы, Кустанайдан;

15) Йосыфхан Садыйкхуҗа угылы, Фрунзе имамы;

16) Закирулла Хуҗаев Тайуб, Сталинабаддан;

---

[1] *Бисмиллаһи Рахмани Рахим* – Мәрхәмәтле, Рәхимле Аллаһның исеме белән.
[2] *Сөбханә вә Тәгалә* – Һичбер кимчелексез һәм Бөек.
[3] *фазыл вә гыйнайәт* – бөеклек һәм ярдәм.
[4] Кулъязмада фамилиясе «Хәстәмирев» дип ялгыш язылган.
[5] *Ташкин* – Ташкент.
[6] *Алмада* – Алма-Ата.

17) Шаһәкрам Исламов, Бохара имамы;

18) Шиһабеддин карый Мөэминев, Аэродромындан[7].

18 кеше.

14 нче агустда сәгать 3-дә Мәскәү аэродромындан очыб, Сталинградка сәгать 6-да 30 минутда килеб җитдек.

7 сәгатьдә 10 минутда китеб, 17 сәгать 20 минутда Бакуга килеб җитдек. Бакуда имам вә голәмалар[8] һәм Баку мөфтисе Ибраһим хәзрәт, мөселманлар истикъбаль идеб[9], аэродромга [килеп] каршылаб алыб, күб хөрмәтләр итделәр.

Бакудан 2 сәгатьдә 30 минутда китеб, сәгать 10 минутда Таһранга килдек. Персия әмирләре салкын караш белән алдылар. *// (2а кәгазь)* Паспортларымызны тәфтиш кылдылар[10]. Анда ике сәгать вакыт үтде. Ниһаять, Фәрдуси нумерында кундык, истирахәт[11] итдек.

Агусның 15-ендә иртән сәгать 5-дә 40 минутда Таһрандан очыб, 8 сәгать 25 минут Бәгъдадка килдек. Бу арада биек таулар булыб, калучылар[12] булды, тәнәфес бирделәр. Аэродром Хәйд Гулаб. Бәгъдад аэродромында самолётыбыз 5 километр биеклеккә очыб, һава җитмәй, буылыб, күгәреб калучыларымыз булды.

Бәгъдаддан 10 минут ким сәгать 10-да очыб, 1 сәгать 25 минутда тәнәфес бирделәр. Бәгъдад аэродромындан Әхмәд Мидхәт, Габдрахман хәзрәтләре истикъбаль итделәр. Гарәбчә мөкяләмәмез[13] булды.

Бәгъдаддан 18 минут ким сәгать 10-да очыб, 1 сәгать 25 минутда Бәйрутка килдек. *// (2б кәгазь)* Бәйрут әмирләре салкын карадылар. Столовайга[14] кереб тамашаландык, хакимләре яһүдиләр иде.

Бәйрутдан 15 минут ким 4 сәгатьдә очыб, 6 сәгать 25 минутда Мисыр Аллаһуга[15] килдек. Мисыр советлары истикъбаль итделәр.

---

[7] Бу урындагы «Аэродромындан» дигән сүз кульъязманы күчерүче тарафыннан ялгыш язылган.

[8] *голәма* – укымышлы дин әһелләре.

[9] *истикъбаль идеб* – каршылап.

[10] *тәфтиш кылу* – тикшерү.

[11] *истирахәт* – ял.

[12] Бу сүз алдында булырга тиешле бер сүз язылмыйча калганга охшый.

[13] *мөкялямә* – әңгәмә.

[14] *столовай* – ашханә.

[15] Бу урында «Аллаһуга» сүзе ялгышлык белән язылгандыр.

Мисырның гәзит хәбәрләрен сораб алдык. Совет иле хәлен сорашдылар. Булган хәлне тугры сөйләб бирдек. Икенче көн хәбәремезгә гәзитләр басылыб чыкды. Янә журналларда басылыб чыкды.

16 нчы агусда сәгать 9-да 30 минутда Мисырдан очыб, Гарәбстан читенә 12 сәгать 30 минутда килеб җитдек. Таһәратләнеб намаз укыдык. Андан очыб Аллаһ[16] Кайсарстанга, андан очыб 5 сәгать 20 минутда Җиддәи мөбарәк[17] аэродромына килдек. *// (3а кәгазь)* Самолётымыз үз дәлил[18] Муса Габдулла васитасилә[19] автобус яллаб, тугры юл белән (17 нче агустда таң алды иде) Мәккәи мөкәррәмәгә сәламәт килеб җитдек. Чумаданларымызны мөтауваф[20] Ибраһимда калдырыб, тугры Кәгъбәтуллага[21] килдек. Тәкрәре ният[22] белән әүвәл Кәгъбәтулланы 7 мәртәбә тәваф кылдык[23]. Соңра Сафа илә Мәрвә тавы арасында 7 мәртәбә сәгый[24] кылдык. Андан кире Кәгъбәтулла[га] килеб, имамга оеб, салавател-фәҗерне[25] укыдык. Кайтыб чәй эчеб истирахәтдә калган идек, дәлилләр килеб безне бүлеб, Ташкентлар дәлил Ибраһимда калдылар, безне – Уфалыларны дәлил Сәруҗи алыб китде. Аның тирәсенә урнашкач, Сәруҗи илән кайтыб Кәгъбәтуллага килеб, бик иркен рәвешдә тәваф кылдык һәм Сафа илән Мәрвә арасында бик иркенләб сәгый кылдык. *// (3б кәгазь)* Кәгъбәтуллага тәваф вакытында Хәҗәри әсвадне[26] үбдек. Шул вакыт күңелемез хушланды.

18 нче агусда янә Кәгъбәтуллада бер мәртәбә булдык. Җыелган хаҗилар фәүкыльгадә[27] күб иде. «Әхбәрел-җәдид» гәзитәсендә җир йөзендә булган ислам мәмләкәтләрендә күбме хаҗи килгәнен

---

[16] Бу урында «Аллаһ» сүзе ялгыш язылгандыр.
[17] *Җиддәи мөбарәк* – мөбарәк Җиддә шәһәре.
[18] *дәлил* – хаҗ кылырга килгән мөселманнарга хаҗ кылу рәвешләрен күрсәтүче һәм өйрәтүче юлбашчы.
[19] *васитасилә* – арадашлыгы белән.
[20] *мөтауваф* – хаҗиларны каршы алучы.
[21] *Кәгъбәтулла* – мөселманнарның Мәккәдәге изге йорты, Изге мәчет.
[22] *тәкрәре ният* – ниятне кабатлау.
[23] *тәваф кылу* – кабул ителгән рәвештә Кәгъбәтулла тирәли әйләнү.
[24] *сәгый* – ике тау арасында йөрү.
[25] *салавател-фәҗер* – таң намазы.
[26] *Хәҗәри әсвад* – Кәгъбә диварындагы изге Кара таш.
[27] *фәүкыльгадә* – гадәттән тыш.

мәгълүм кыйлынды: 500 меңдән артык хаҗилар булганы басылыб чыкды.

19 нчы агусда тагын да Гарәфәт тавына килеб вокуф[28] кылдык. Ак тәвә [ягъни, дөя] өстендә утырыб вәгазь сөйләгәнен, имамның хотбәсен тыңладык, күб гыйбрәтле хәлләр күрдек.

20 нче агусында тагын да Мөздәлифәдән Мина тавына килдек. Фәүкыльгадә халык биниһайә[29] күб иде. Һава кызулык алтмыш градуска җитде. Икешәр йөз сум хак биреб, берәр сыгыр[30] сатыб алыб, 7 кеше исемендән корбан чалдык. Тәкаббәлә Аллаһы Тәгалә[31]!

Менә шул көнне Мәккәи мөкәррәмәгә кайтыб, Кәгъбәтулла җиварында[32] *// (4а кәгазь)* җомга намазы укыдык. Кич янә Мина тавына өч мәртәбә урынга барыб, рамиэл-хәҗәр[33], гомран[34] тәмам итеб, агустның 21-ендә[35] Мәккәи мөкәррәмәгә кайтыб, янә Кәгъбәтулланы тәваф әйләб, ихрамдан[36] чишелдек. Әлхәмде ли-Ллаһи, хаҗи әлхәрам[37] булдык. Бер-беремез илә кочаклашыб күрешдек. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәтләрендән кабулият[38] теләб дога кыйлдык.

3 нче көн янә Мәккәи мөкәррәмәдә булдык. Маэи зәмзәм[39] эчдек, алыб кайту өчен сатыб алдык. Башка хаҗ һәдияләрен[40] алдык. Шулай да һәр көн Кәгъбәтуллага барыб шәрафәтләндек, вагыйзьләр һәм карыйлар хозурында булдык.

25 нче агусда тәвафел-видагъ[41] кылыб, дәлил Сәруҗи илән хисаблашыб, фатыйхасын алдык. Үзенә тиешле мәсрафын[42] биреб,

---

[28] *вокуф* – басып тору. Кульязмада «вакыйфә» дип язылган.
[29] *биниһайә* – чиксез.
[30] *сыгыр* – сыер.
[31] *Тәкаббәлә Аллаһы Тәгалә* – Аллаһы Тәгалә кабул кылсын!
[32] *җивар* – ян, тирә.
[33] *рамиэл-хәҗәр* – таш ату. Кульязмада бу сүз хаталы язылган.
[34] *гомран* – җиренә җиткереп.
[35] Бу дата ялгыш язылган булса кирәк. Дөресе – 22 август булгандыр.
[36] *ихрам* – хаҗилар киеме.
[37] *хаҗи әл-хәрам* – хаҗи (изге урыннарга хаҗ кылган кеше).
[38] *кабулият* – кабул кылыну.
[39] *Маэи Зәмзәм* – Зәмзәм суы.
[40] *һәдия* – бүләк.
[41] *тәвафел-видагъ* – хушлашу тәвафы.
[42] *мәсраф* – хак, акча.

һәдия итеб чапан ябдык. *// (4б кәгазь)* Өю[43] эчендә булган гаиләсен дә бүләкләр белән тамаша әйләдек һәм бәмшисир[44] бирдек. Вәдагълашыб[45] паспортларыбызны кулыбызга алыб, автобуз белә Җиддәи мөбарәккә китдек.

Анда бер көн торыб, Мәдинәи мөнәүвәргә сәфәр кылдык.

28 нче агустда Мәдинәи мөнәүвәрә мәсҗидендә гаммамәдә[46] җомга укыдык. Имам гаять дә фәсыйх[47] хотбә укыды. Гарәб мәкаме[48] белән дөрест итеб кыйраәт кылды[49]. Шул көнне икенде намазын[50] Мәсҗиде Хәрам, Раудаи Моттаһарага[51] барыб укыб, бәгъдәлгаср[52] Раудаи моттаһара хәббәсенә[53] килеб, Рәсүлулла салал-лаһы галәйһис-сәлямгә сәлам биреб, салават укыб, Коръән укыб дога кылдык. Хаҗилар күб булу сәбәбле, туктаб торыб булмады.

29 нчы агусда дәлилнең юлбашлыгы илән[54] Мәдинәдән 10 километр ераклыкта булган Мәсҗиде Коббага барыб, *// (5а кәгазь)* Рәсүлемезнең беренче мәртәбә җомга укыган мәсҗиден күреб тамаша кылдык. Өхед сугышында шәһид булган шәһидләр каберенә барыб зиярәт кылдык. «Мәсҗиде Кыйблатәйн»дә булдык. Әүвәлдә китабда укыб кына белгән хәл-вакыйгаларны биззат[55] күзебез белән күрдек һәм дөрест табдык.

Мәдинәи мөнәүвәрәдә карый Хәсән хәзрәтдә 18 кеше миһман[56] булдык. Кыйраәтемезне тыңлатдык. «Бәрәка-Ллаһ, маша-Ллаһ, Русия илендә дә мондай карыйлар бар икән!» – диб, бик шадландылар.

---

[43] *өю* – өй.
[44] *бәмшисир* – ?
[45] *вәдагълашыб* – хушлашып.
[46] *гаммамә* – чалма.
[47] *фәсыйх* – матур тел белән.
[48] *мәкам* – көй.
[49] *кыйраәт кылу* – Коръән уку.
[50] *икенде намазы* – төштән соң Кояш баеганчы ике арада укыла торган намаз.
[51] *Раудаи Моттаһара* – Мөхәммәт пәйгамбәр кабере урнашкан изге урын.
[52] *бәгъдәл-гаср* – икенде намазыннан соң.
[53] *хәббә* – мәйдан, урын.
[54] *илән* – белән.
[55] *биз-зат* – шәхсән, үзебез.
[56] *миһман* – кунак.

Мәдинәдә күб торыб, һәр көн Раудаи моттаһарага барыб зиярәт кылыб, әлхаҗел-хәрәмәйн булдык.

Сау-сәламәт Җиддәи мөбарәккә килеб, үземезнең килгән самолётыбызга утырыб, кайту сәфәренә чыкдык. *// (5б кәгазь)* Беренче мәрхәмен[57] Тур Синада карантинга очраб, анда 3 көн ятдык.

Андан Мисырга килеб, Мисыр шәһәрен дә тамаша кыйлдык. Җамигълар[58] һәр «Җамигы Раффагый», «Җамигы Мөхәммәд Гали шаһ», «Җамигы Шөһәдәи Хөсәен»ләрне күреб, Мисыр мөфтисе Мөхәммәд Хөсәен Мәхмүдев хәзрәтендә һәм совет посолында миһман булдык.

9 нчы сентябрьдә Мисырдан чыгыб, Бәйрут, Бәгъдад, Таһран, Баку аркылы, Сталинград аркылы 12 нче сентябрьдә Мәскәүгә саусәламәт кайтдык.

Әлхәмделилләһи шөкер, аэродромдан Бабаханов, мөтәвәллиләр[59], мөселманлар каршы алдылар. Шуның илән тәмам итдек. Амин! Йа, Раббил-галәмин!

Һәм ошбу хаждан кайткан китабны кабул күреб, алыб укучыларга һәм тыңлаучыларга мөэмин-мөселман кардәшләргә Аллаһы Тәгалә әҗерен насыйб әйләсен! Амин! Йа, Мөҗибес-саилин[60]. Бихөрмәти сәйидел-мүрсәлин[61], бирәхмәтикәи, йә, Әрхәмер-рахимин!

[Мөфти Шакир Хәялетдинов].

---

[57] *мәрхәм* – тукталыш.
[58] *җамигъ* – җамигъ мәчет.
[59] *мөтәвәлли* – мәчет эшләрен башкаручы.
[60] *Мөҗибес-саилин* – дога-теләкләрне кабул итүче.
[61] *бихөрмәти сәйидел-мүрсәлин* – пәйгамбәрләрнең иң олугы (ягъни, Мөхәммәт пәйгамбәр) хакына.



1 (1)

بسم الله الرحمن الرحيم

الله حق سبحانه وتعالى فضل و عنايتى نصيب قلدى

حكومتمز سوويت دولتنڭ رخصتى بلان

1953 يلده 14 نچى آغوستده تاڭده ساعت

3 ده حاج سفرينه نيت ايدوب

18 كشى دعولد بلان آلغان سمولتقه اوتروب

حاج سفرينه يولغه چقدق )

حاج سفرنده يولداشلارمز

1) بنى ميفتى حضرت شاكر فيال الدينف اوفادن

2) قاضى ياراللّٰه حضرت يوسوف پينزا ايماى

3 اسماعيل مستميرف قازان ايماى

4 اسماعيل رحمة اللين مسكاو ايماى

5 عبدالبارى يونسف ايشانباى ايماى

6 عبدالبارى ايسايف اوفا زيارت مسجد ايماى

7 قاضى ضياء الدين ايشان باباخانف تاشكيندن

8 فضل خوجه صادق خوجه اوغلى تاشكيندن

9 ساكران علمانف آلما آتادن

10 عبد الحفيظ اسماعيلوف تاشكيندن

11 اسماعيل [illegible] [illegible]


ТАТАРСТАН МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕ
КУЛЪЯЗМАЛАР
ҺӘМ СИРӘК КИТАПЛАР БҮЛЕГЕ
НАЦИОНАЛЬНАЯ БИБЛИОТЕКА РТ
ОТДЕЛ РУКОПИСЕЙ И РЕДКИХ КНИГ
559т


*Кулъязманың факсимилесе. 1а кәгазь.*


(٢)

12 مینهاج الدین قاری عبدالله اوغلی تاشکیننددان

13 عبدالرحیم محمد اوغلی ترکمان اومسدانددان

14 عبدالباری صابر اوغلی کوستانای‌دان

15 یوسف خان صادق خوجه اوغلی فرونزی ایمامی

16 ذاکرالله خوجایف طلیب استالین آباددان

17 شاه اکرام ایسلاموف. بخرا ایمامی

18 شهاب الدین قاری مؤمینوف آیردرومندان

18 کشی

14 نی آغوستده ساعت ٩ ده مسکاوا آیرودرومندان
اوچوب استالین گرادقه ساعت ١٢ ده
٣٠ مینوتده کیلب جیتدک
٧ ساعتده ١٥ مینوتده کیتوب
17 ساعت ٢٠ مینوتده باکوغه کیلب جیتدک
باکوده ایمام وعلماءلر هم باکو مفتی‌سی ابراهیم
حضرت مسلمانلار استقبال ایدوب آیرودرومده
قارشلاب آلب کوب حرمتلی ایتدیلر باکودان
٢ ساعتده ٣٠ مینوتده کیتب ساعت ١٠ مینوتده
طاهرانغه کیلدک پیرسیه امیرلری
صالقین قارش بلان آلدیلار.

*1б кәгазь.*

2 (3)

پاشپورتلارمزنی تفتیش قلدیلار ،
آنده ایکی ساعت وقت اوتدی نهایت
فردوس نومیرنده قوندق .
استراحت ایتدک آعوستنک 5/ نده
ایرته‌ن ساعت 5 ده 40 مینوتده
ظاهراندن اوچب 8 ساعت 25 مینوت
بعد انقره کیلدک بوآراده بییک تاولار بولب )
قالوچیلار بولدی تنفس بیردیلر
آیرودروم حید علاب بعدات آیرادروم‌نده
سماولوتبز 5 کیلا میتر بییک لکگه اوچب
هوا جیتمه‌ی بوولب کوگه‌روب
قالوچیلارمز بولدی ،
بعداتران 10 مینوت کیم ساعت 10/ نده
اوچب 1 ساعت 25 مینوتده
تنفس بییردیلر . بعدات آیرودرومندان
احمد مدحت عبدالرحمن حضرتلی استقبال
ایتدیلار عزیزچه مکالمه‌مز بولدی
بعداتران 18 مینوت کیم ساعت 10/ بنده اوچب
1 ساعت 25 مینوتده بیروتقه کیلدک

*2а кәгазь.*

(٦)

بیروت امیرلەری صالقون قارادیلار
استالاوایغه کروب طاماشالالدق
حاکیملەری یهودیلی ایدی . بیروتدان
١٥ مینوت کیم ٤ ساعتده اوچب ٦ ساعت
٢٥ مینوتده مصر اللّٰه هوگه کیلدک
پاسولشتیفاش مصر ساویتلەری
استقبال ایتدی لار مصرنک گازیت
خەبەرلەرگن صوراب آلدق
ساویت ایلی حالن صراشدی لار
بولغان حالنی توغری سویلاب بیردک
ایکنچی کون خەبەرگه گەزیت لەر
باصلوب چقدی ینه ژورناللرده باصلب
چقدی ١٦نچی آغوستده ساعت ٩ دە
٣٠ مینوتده مصردان اوچب ،
عربستان جیتنه ١٢ ساعتده ٣٠ مینوتده
کیلوب جیتدکده . طهارت لەنب نماز اوقدق
آندان اوچب اللّٰه قیسر استانغه
آندان اوچب ٥ ساعت ٢٠ مینوتده
جمعهٔ مبارەک اوردومنه کیلدک

*2б кәгазь.*


3 5

سمالوتمز اوز ذلیل موسی عبدالله واسطاسیله
افتابوضنز یاللاب توغری حجّ‌یون بلهن
17 نچی آغوستده تانک آلدی ایدی
مکهٔ مکرّمه‌گه سلامت کیلب جیتدک
چومادانلارمزنی (مطوّف) ابراهیم دا قالدروب
توغری کعبة الله غه کیلدک
تکرار نیّت بلهن اوّل کعبة اللهنی 7 مرتبه
طواف قلدق .
صنکرا صفا ایلن مروا تاوی آراسنده 7 مرتبه
سعی قلدق
تانکدان کیری کعبة اللهکه کیلب امامغه ایبوب
صلوة الفجرنی اوقدق قایتوب چای اچوب
استراحتده قالغان ایدک ذالیل‌لار کیلب
بزنی یولب تاشکینتلی ذالیل ابراهیم ده
قالدرلار . بزنی اوغالیلار ذالیل سروجی
آلب کیتدی تانک تیره سنه اوزنا شقایج
سروجی ایلان قایتوب کعبة الله غه کیلب
بیک ایرکلن رهوشده طواف قلدق
ہ صفا ایلن مرو آراسنده بیک ایرکنلهب

*3а кәгазь.*



(٥)

کعبة اللهغه طواف وقتنده حجر الاسودنی
اوبدک شول وقت کوکلم خوشلاندی
18 نچی آغوستده ینه کعبة اللهده برمرتبه بولدق
جیلغان حاجیلار فوق العاده کوب ایدی
امبر الجدید گازیته سنده جیریوزنده
بولغان اسلام مملکتلرنده کوبچی حاجی کیلگانن
معلوم قیلندی ۵۰۰ مکدان آرتق حاجیلار
بولغانی با مثلب چقدی
۱۹ نچی آغوستدا تاغنه عرفات تاوینه کیلب
واقفغه قالدق آق تاوه اوستنده اوتروب
واعظ سویلیگانن امامنک خطبه سن تکلادق
کوب عبرتلی حاللر کورد(ک) کوردک
۲۰ نچی آغوستنده تاغنه مزدلفهدن
منیه طاوینه کیلدک فوق العاده حالق بنهایه
کوب ایدی. هوا قزولغی اللتمش گرادسقه جتدی
ایکنچیدن سوم حاق بیروب بوعدهر
صاتوب آلوب ۷ کشی اسمدان قربان چالدق
تقبل الله تعالى . منه شول کونی
مکه مکرمهگه قایتوب کعبة الله جوارنده

3б кәгазь.



4 (7)

جمعه نمازی اوقدق کیچ ینه منا طاوینه
اوچ مرتبه اورنغه باروب رامی الجمر
عمران تمام ایتب آغوستننک 22 نده مکهٔ مکرمه‌گه
قایتوب ینه کعبة الله نی طواف ایلب احرامدان
چیشنلدک الحمد لله حاجی الحرام بولدق
بر برمز ایله قچاقلاشب کورشدک
الله تبارک و تعالی حضرتلرندان قبولیت تلب
دعا قیلدق 23 نچی کون ینه مکهٔ مکرمه‌ده
بولدق ماء زمزم ایچدک
آلوب قایتو اوچن صاتوب آلدق
باشقه حاجی هدیه‌لرنی آلدق سوغایه
هرکون کعبة الله‌گه باروب شرافت له‌ندک
واعظلرنی قاریلار حضورنده بولدق
25 نچی آغوستده طواف الوداع قلنب
دلیل سروجی ایله‌ن حسابلاشوب
فاتحه‌سون آلدق.
اونده یتوشلی مصاره‌نی بیروب
هدیه‌یه ایتوب چابان یابدق

*4а кәгазь.*

(8)

ایبیو اچنده بولغان عائله سنده بولهکلر بله ن
تماشه ایله دک هم تمشیسیز بیردک
وادعلاشوب پاشپورتلاریمزنی قولیمزغه
الوب آفتابوز بله جده ٔ مبارکگه کیتدک
آنده بر کون تروب مدینه ٔ منوره گه
سفر قلدق 28 نچی آغوستده
مدینه ٔ منوره مسجدنده نمازلرده
جمعه اوقدق . امام عائشه فاصیب خطبه
اوقدی عرب مقامی بلهن . درست ایتوب
قراءت اوقدی شول کوننی ایکندی نمازین
مسجد حرام روضه ٔ مطهره غه باروب اوقب
بعد العصر روضاء مطهره جنته سنه کیلب
رسول الله صلی الله علیه السلامغه سلام بیروب
صلوات اوقب قرآن اوقوب دعاء قلدق
حاجیلا کوب بولو سببلی طوقتاب تروب
بولمادی 29 نچی آغوسده دلیلنک بول
باشلوی ایلهن مدینه دهن 10 کیلا میتر
یراقلقتا بولغان مسجد قباغه باروب

*4б кәгазь.*

5 (٩)

رسولمزنڭ برنچی مرتبه جمعه اوقوغان
مسجدن کوروب طاماشا قلدق
اُحُد سوغشنده شهید بولغان شهیدلر
قبرینه باروب زیارت قلدق
مسجد قبلتینده بولدق اوّلده کتابده اوقوبقنه
بلگان حال وقیفلارنی باالطن کوزمز بلان
کوردک هم درست طابدق
مدینهٔ منوره‌ده قاری حسن حضرت‌ده
18 کشی مهمان بولدق قرآنمزنی تنگلاتدق
بارک الله ماشاء الله روسیه ایلنده
موندای قاریلار بارایکان دیب بیک شادلاندیلار
مدینه‌ده کوب توروب هر کون
روضهٔ مطهره‌گه باروب زیارت
قلب الحاج الحرمین بولدق
صاو سلامت جده مبارکه‌گه کیلوب
اوزمزنڭ کیلگان سمالوتمزگه اوتروب
قایتو سفرینه چقدق

*5а кәгазь.*

(۱/٥)

بونی مرتچلینی طور سیناغه ده کرانتینگه
اوچراب آنده اوچ کون یاتدق آندان مصرغه
کیلب مصر شهرنه طاماشا قیلدق
جامیع لار هم جامیع رفاعی جامع محمد علی شاه
جامع شهسه حسینی لارنی کوروب
مصر مفتی سی محمد حسین محمودف حضرتونده
هم ساویت پاسلونه میهمان بولدق
و نی سینتا۲ برده مصردان چقب
بیروت بغداده طهران باکو آرقلی
استالین گرات آرقلی ۱۲ نچی سینتا برده
مسکاوگه صاو سلامت قایتدق
الحمدلله شکره آیرادروهدان بابا جانف
متولیلر مسلمانلر قادشی آلدیلار
شونک ایله تمام ایتدک آمین
یارب العالمین هم اشبو حاجیلان
قاشقان کیتابنی قبول کوروب آلب
اوقوچیلارغه هم تنگلاوچیلارغه
موءمین مسلمان قرده شلرگه

*5б кәгазь.*


6 (11)

الله تعالى حضرتى اجرن ناصيب ايله سون
امين يا مجيب السائلين
بحرمة سيد المرسلين بحرمتكك
يا ارحم الراحمين

الٓمٓ ذٰلِكَ الْكِتٰبُ لَا رَيْبَ فِيهِ هُدًى لِلْمُتَّقِينَ
الَّذِينَ يُؤْمِنُونَ بِالْغَيْبِ وَيُقِيمُونَ الصَّلٰوةَ وَمِمَّا
رَزَقْنٰاهُمْ يُنْفِقُونَ .
وَالَّذِينَ يُؤْمِنُونَ بِمَا اُنْزِلَ اِلَيْكَ وَمَا اُنْزِلَ
مِنْ قَبْلِكَ وَبِالْاٰخِرَةِ هُمْ يُوقِنُونَ
اُولٰئِكَ عَلٰى هُدًى مِنْ رَبِّهِمْ وَاُولٰئِكَ هُمُ الْمُفْلِحُونَ

*6а кәгазь.*

## КУЛЪЯЗМАЛАРНЫҢ ТАСВИРЛАРЫ

### XVIII гасыр татар хәрбиенең юлъязмасы

Кулъязма 15,5х20 см зурлыктагы, ике яклары да язулы өч кәгазьдән гыйбарәт.

Текст тулы түгел, аның башындагы берничә сүзе танылмый һәм соңгы битләре сакланмаган. Ул саргылт, начар сыйфатлы рус кәгазенә язылган.

Текстның башы (1б кәгазьдә): *вакытда йазылды бу язу*.

Ахыры (3б кәгазьдә): *...ул өйәзендә.*

Кулъязманың сакланышы начар. Сыек саргылт язу карасы вакытлар үтү белән уңган һәм язулар күп урыннарда бөтенләй күренмәслек дәрәҗәгә килгән. Бит читләре таушалган Шуның өстенә кәгазенең бозылып, күгелҗем күгәрек төсенә керүе сәбәпле, язулар бик авыр таныла.

Текстның язылу вакыты үзендә 1756 елда дип күрсәтелгән.

Кайда язылган булуы һәм авторы билгесез.

Кулъязманың 1а кәгазендә нәсел шәҗәрәсе фрагменты сакланган. Ихтимал, ул шушы кулъязма авторы нәселедер. Кызганычка каршы, шәҗәрә язулары уңган. Шулай да танылган кадәр фрагментларын монда күчерәбез.

«Әүвәл бабамыз Биккенә (?), бунның [угыллары]: берсе – Алмакай, берсе – Карача, Мостай.» Алмакай исеменнән түбәндә: «Аның угылы Йуванай, аның угылы Кана...». «Йаңкул кызы безнең апамыздыр, кай... һәм Йаңкул кызы. Вә йәнә Өчкүлнең ... угылы Йаңкул берлән бертуганның угылы. Вә һәм ... берлән бертуган Зәмәй угылы Се[н]бернең Иске Кәкрелед[ә]. Зәмәй угъланлары: Йәмәй, Мөкәй, Госман. Госма[н] угылы Максут шул ук Алатур өйәзендә Печә... Чирүченең анасы Ислан берлән бертуган Мәверәй (?) кызы. Вә йәнә Йомран авылының Чирүченең анасы Йаңк[ул] кызы. Гос-




*«1052 т» шифрлы кулъязманың*
*шәҗәрә фрагменты язылган 1а кәгазе.*

ман Мөхәммәд мулланың ...ның атасы Калмук, Ходайбирде бертуган...»

Шул ук биттә фарсы телендә һәм төрки-татарча икешәр юллык шигырьләр язылган. Алар тулаем танылмыйлар. Шунда ук рус хәрефләре белән хаталы итеп берничә сүз язылган.

Бу кульязманың палеографик үзенчәлекләреннән «уау» хәрефенең өстенә өч нокта куелуын әйтергә кирәк. Шул ук хәрефнең һәм «дәл» хәрефенең, гарәп имлясының гомуми кагыйдәсеннән тайпылыш буларак, үзләреннән соң килгән хәрефкә тоташтырып язылган урыннар да бар. Тексттагы сүзләрдә «гәф» хәрефе «ң» хәрефе белән белдерелгән.

Кульязма истәлекне Татарстан Милли китапханәсенә Уфа шәһәрендә яшәүче Нурдидә Биктимерова тапшырды. Ул аңа бүтән кульязма истәлекләр белән бергә Башкортстанның Чишмә районы Сәйран авылында яшәп, 1943 елда вафат булган Абдулла Сәйфуллиннан калган.

Хәзер бу кульязма китапханәнең Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «1052 т» шифры белән саклана.

Бу кульязманың тексты һәм аның турында мәгълүмат басылды:

1. «Язылды бу язу 1756 елда...» // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2002. – №1/2. – Б.16–18.

2. Мәрданов Р. Тарих битләрен актарганда... // Казан утлары. – 2002. – №3. – Б. 131.

3. Марданов Р. Сбережения // Татарский мир = Татар дөньясы. – 2005. – Январь (№23–24).

4. Мәрданов Р.Ф. Китапларда милләт язмышлары... – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2010. – Б. 65. – («Татар археографиясе» сериясе; 5 нче китап).

## Кырым сәяхәтнамәсе

Бу кульязманың авторы Гобәйдулла Рәхмәтулла улы турында кыскача мәгълүмат сәяхәтнамәнең кереш мәкаләсендә бирелде.

Кульязмага «Кырым сәяхәтнамәсе» дигән исем безнең тарафтан куелды.

Текст 14,5х18 см зурлыгындагы юллы дәфтәргә язылган. Дәфтәрнең тышлыгы сакланмаган. Дәфтәр битләре ак һәм кара җепләр белән тегелгән.

Текстның башы (1а кәгазьдә): *Мин, Хәдичә ике баласы белән...*

Ахыры: (16а кәгазьдә): *...кырымлар "Кизләү" диб җөртәләр.*

Текстның күпчелек өлеше шәмәхә кара белән, гарәп язуының тәгълик төрендә язылган. Аерым өлешләре яшькелт (8б кәгазьдә) һәм кара (13б кәгазьдә) төсләрдәге каралар белән язылган.

Дәфтәрнең сакланышы уртача. Дәфтәрнең уртасыннан эләктерелгән тимер беркеткече күгәреп өзелгән. Ахырына өстәлгән шакмаклы дәфтәрнең бер бите теккән җебеннән аерылган.

Текст 1937–1938 елларда автор кулы белән язылган. Тик аның үзендә автор исеме язылмаган. Гобәйдулла Рәхмәтулла улының китапханәдә «1081 т» һәм «1083 т» шифрлары белән саклана торган бүтән кулъязмалары ярдәмендә авторның исеме ачыкланды.

Дәфтәргә автор тарафыннан бит саннары куелмаган.

Бу дәфтәр Татарстан Милли китапханәсенә Казан шәһәрендә яшәүче Габделхак Хәсәновтан 1995 елның 16 ноябрендә алынды. Хәзерге вакытта китапханәнең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «657 т» шифры белән саклана.

Дәфтәрнең соңгы 16 нчы кәгазенең ике ягында да авторның башка төр язулары (адреслар һ.б.) теркәлгән.

Бу кулъязманың тексты һәм аның турында мәгълүмат басылды:

1. Сагындыра иде Кукмара... // Хезмәт даны (Кукмара). – 1997. – 25, 29 гыйнвар; 5 февраль.

2. Мәрданов Р. Тарих битләрен актарганда... // Казан утлары. – 2002. – №3. – Б. 131–132.

3. Гобәйдулла Рәхмәтулла улы. Кырым сәяхәтнамәсе // Мәйдан. – 2003. – №1. – Б. 106–114.

4. Марданов Р. Сбережения // Татарский мир = Татар дөньясы. – 2005. – Январь (№23–24).

5. Мәрданов Р.Ф. Китапларда милләт язмышлары... – Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2010. – Б. 65. – («Татар археографиясе» сериясе; 5 нче китап).

## 1945 елгы Хаҗ сәфәре

Бу текстның мөфти Габдрахман Рәсүли тарафыннан дусларына язылган хат булуы кулъязманың үзендә күрсәтелгән.

Кулъязмада текстның исеме юк.

Кулъязма 20х29 см зурлыктагы, өске ягыннан ак җеп белән тегелгән калын дүрт кәгазьдә. Хаҗнамә тексты шуның 1а, 1б һәм 4б кәгазьләренә теркәлгән. Ә 2б һәм 3б кәгазьләрдә шул ук текстның 4б кәгазендәге өлешенең копировка аша төшерелгән нөсхәләре. Бу исә текстны күчергеч кәгазь ярдәмендә күбәйтеп, халык арасында таратылган булу фактын дәлилли.

Текст бөтен хәлендә. Башы (1а кәгазьдә): *Бу язу Диния Нәзарәтенең...*

Ахыры (4б кәгазьдә): *...иннәкә әнтә Гафурур-Рәхим.*

Текст гарәп язуының нәсех төрендә, гади карандаш белән эре хәрефле итеп язылган.

Кулъязманың сакланышы яхшы.

Күчерелгән вакыты һәм урыны язылмаган. Шулай ук кем тарафыннан күчерелгән булуы да күрсәтелмәгән.

Бу хаҗнамә хәзерге вакытта Татарстан Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «1012 т» шифры белән саклана.

## 1953 елгы Хаҗ сәфәре

Бу хаҗнамә тексты 8 кәгазьле, 12х17 см зурлыктагы, юллы кәгазьдән гыйбарәт дәфтәргә теркәлгән. Дәфтәр төбеннән кара җеп белән тегелгән, тышлыгы юк.

Хаҗнамәнең тексты тулы, ул дәфтәрнең 1а–6а кәгазьләрендә (үз пагинациясе буенча 1–11 битләрдә) язылган.

Текстның башы: (1а кәгазьдә): *Бисмиллаһи рахмани рахим. Аллаһы Хакъ Сөбханә вә Тәгалә...*

Ахыры (6а кәгазьдә): *...йә, Әрхәмер-рахимин.*

Текст дәфтәргә зәңгәр кара белән, гарәп язуының нәсех төрендә язылган.

Кулъязманың сакланышы яхшы.

Хаҗнамә авторының исеме кулъязманың үзендә әйтелмәсә дә, аның мөфти Шакир Хәялетдинов булганлыгын чамаларга мөмкин.

Текстның күчерелгән вакыты һәм урыны, кем тарафыннан күчерелгән булуы күрсәтелмәгән. Шулай да вакытын 1953–1960 нчы еллар арасында дип әйтергә мөмкин.

Бу дәфтәр Татарстан Милли китапханәсенә Татарстанның Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче Хәния Хәсәншинадан 1993 елның 14 маенда алынды. Хәзерге вакытта китапханәнең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «559 т» шифры белән саклана.

Дәфтәрнең 6а кәгазендә Коръәннең «Бәкарә» сүрәсенең башындагы биш аяте язылган. Ә 6б–8б кәгазьләрдә Аллаһы Тәгаләнең сыйфатлары һәм аларның дәлилләре сорау-җавап рәвешендә язылган.

## РЕЗЮМЕ

Восьмая книга серии «Татарская археография» представляет собой публикацию четырёх текстов путевых заметок, хранящихся в Отделе рукописей и редких книг Национальной библиотеки Республики Татарстан.

Жанр путевых заметок в духовной культуре татарского народа имеет давние традиции. Науке известны описания путешествия Исмагила Бикмухамметова в Индию в 1751 году, путешествия Мухамметамина Гумерова в восточные страны в 1780 году, описания путешествий мусульманских паломников (хаджи). Многие из них переписывались и таким образом распространялись.

В Национальной библиотеке Республики Татарстан хранятся списки вышеназванных и других путевых заметок, принадлежащих перу татарских авторов. Для полноты информации добавим, что позднее – в XIX веке–начале XX века – были напечатаны книги о путешествиях известного историка и богослова Шигабутдина Марджани (1818–1889) в Турцию и арабские страны, Загира Бигиева (1870–1902) – в Среднюю Азию, Фатыха Карими (1870–1937) – в Крым и Европу, Садретдина Максуди (1878–1957) – в Англию и др.

В данном сборнике представлены тексты путевых заметок 1756, 1937-1938, 1945 и 1953 годов.

В первой из них – рукописи военнослужащего татарина – описан маршрут похода 1756 года, начавшегося близ города Уфы и завершившегося на нынешней территории Черниговской области Украины. Участники похода направлялись на войну, позднее получившую название Семилетней. В этом тексте содержится интересная информация о цыганах и донских казаках. Ввиду плохой сохранности документа, текст публикуется с сокращениями.

Автор второго текста – Губайдулла Рахматуллин (1868 года рождения) – уроженец деревни Туркаш Кукморского района Рес-

публики Татарстан. Вместе с другими односельчанами, видимо будучи завербованным, он в 1937 году направился в Крым, где находился в течение полутора лет на заработках. Автор описал немало интересных фактов, характеризующих  хозяйственную жизнь, климат, селения и народности Крыма, среди которых крымские татары, немцы, болгары, греки, евреи, караимы. Автор указал этнографические особенности крымских татар. В записках Г.Рахматуллина отражены и такие события тех лет, как репрессии, раскулачивание, закрытие мечетей и церквей.

Путевые записки 1945 и 1953 годов представляют собой описание путешествия мусульманских паломников из Советского Союза в Саудовскую Аравию под руководством муфтиев Габдрахмана Расули (1881–1950) и Шакира Хаялетдинова (1890–1974).

Издание снабжено вступительной статьей, описанием рукописей, иллюстрировано образцами факсимиле рукописей.

Эчтәлек

*Төзүчедән* ........................................................................................... 3

XVIII гасыр татар сугышчысының юлъязмасы .................................. 5

Гобәйдулла Рәхмәтулла улы. Кырым сәяхәтнамәсе ...........................19

Габдрахман Рәсүли. 1945 елгы Хаҗ сәфәре ...................................... 51

Шакир Хәялетдинов. 1953 елгы Хаҗ сәфәре .................................... 58

Кулъязмаларның тасвирлары .............................................................. 75

Резюме ................................................................................................. 81

**ПУТЕВЫЕ ЗАПИСКИ**
(на татарском языке)

Ответственный редактор: Ирек Хадиев
Оформление: Шамиль Насыров
Корректор: Миляуша Шакирова

Басарга кул куелды 14.11.2011. Форматы 60x84 1/16.
Тиражы 300 данә. Заказ №286.
Татарстан Республикасы Милли китапханәсе.
«Милли китап» нәшрияты.
420111, Казан шәһәре, Кремль ур., 33.

Подписано к печати 14.11.2011. Формат 60x84 1/16.
Тираж 300 экз. Заказ №286.
Национальная библиотека Республики Татарстан.
Издательство «Милли китап».
420111, г. Казань, ул. Кремлевская, 33.

Отпечатано в секторе множительной техники
редакционно-издательского отдела
Национальной библиотеки Республики Татарстан.
420111, г. Казань, ул. Кремлевская, 33.